УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

ПРИКАЗ
03.07.2015

БОЕРЫК
№ 01-05/112-пр.

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төрдәге техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең кешеләр гомере һәм мөлкәте өчен иминлекне, әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итү өлешендә агросәнәгать комплексында машиналарны һәм җайланмаларны эксплуатацияләү кагыйдәләрен, шулай ук стандартлар, норматив документлар белән регламентлана торган кагыйдәләрне үтәүгә дәүләт күзәтчелеге буенча дәүләт вазыйфасын башкару буенча административ регламентын раслау турында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге № 294-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 21 апрелендәге № 69-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт вазыйфаларын башкаруның административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.12.2012 № 1192 карары нигезендә **боерык бирәм:**

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төрдәге техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең кешеләр гомере һәм мөлкәте өчен иминлекне, әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итү өлешендә агросәнәгать комплексында машиналарны һәм җайланмаларны эксплуатацияләү кагыйдәләрен, шулай ук стандартлар, норматив документлар белән регламентлана торган кагыйдәләрне үтәүгә дәүләт күзәтчелеге буенча дәүләт вазыйфасын башкару буенча административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төрдәге техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе башлыгының «Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелеге идарәсенең Административ регламентын раслау турында» 30.01.20*12 № 6-пр боерыгының үз көчен югалтуын танырга.

3. Дәүләт күзәтчелеге буенча дәүләт вазыйфасын башкарганда Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төрдәге техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең (алга таба – Идарә) вазыйфаи затлары расланган Административ регламентка таянырга тиеш.

4.Идарәнең оештыру-хокукый эш бүлеге башлыгы (Л.М.Аблеева) әлеге боерык белән, имза салдырып, Идарә аппараты бүлекләре башлыкларын һәм Идарәнең күзәтчелек вазыйфаларын башкаручы территориаль бүлекләре вазыйфаи затларын таныштырырга тиеш.

5.Теркәү, автоматлаштырып исәпкә алу һәм махсус эш секторы (М.Ш.Аймалетдинов) әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Хөкүмәте порталында «Дәүләт контроле» бүлегендә урнаштырырга тиеш.

6.Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык Р.Р.Зыятдинов

Татарстан Республикасы
Үзйөрешле машиналарның һәм
башка төрдәге техниканың техник торышына
күзәтчелек идарәсенең
03.07.2015 № 01-05/112-пр боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАРНЫҢ ҺӘМ БАШКА ТӨРДӘГЕ ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕНЕҢ КЕШЕЛӘР ГОМЕРЕ ҺӘМ МӨЛКӘТЕ ӨЧЕН ИМИНЛЕКНЕ, ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ МОХИТНЕ САКЛАУНЫ ТӘЭМИН ИТҮ ӨЛЕШЕНДӘ АГРОСӘНӘГАТЬ КОМПЛЕКСЫНДА МАШИНАЛАРНЫ ҺӘМ ҖАЙЛАНМАЛАРНЫ ЭКСПЛУАТАЦИЯЛӘҮ КАГЫЙДӘЛӘРЕН, ШУЛАЙ УК СТАНДАРТЛАР, НОРМАТИВ ДОКУМЕНТЛАР БЕЛӘН РЕГЛАМЕНТЛАНА ТОРГАН КАГЫЙДӘЛӘРНЕ ҮТӘҮГӘ ДӘҮЛӘТ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ВАЗЫЙФАСЫН БАШКАРУ БУЕНЧА АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Административ регламент кешеләр гомере һәм мөлкәте өчен иминлекне, әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итү өлешендә агросәнәгать комплексында машиналарны һәм җайланмаларны эксплуатацияләү кагыйдәләрен, шулай ук стандартлар, норматив документлар белән регламентлана торган кагыйдәләрне үтәүгә дәүләт күзәтчелеге буенча дәүләт вазыйфасын (алга таба тиешенчә – дәүләт вазыйфасы, дәүләт күзәтчелеге) башкаруның административ процедуралары (Россия Дәүләт техник күзәтчелеге идарәсенең һәм Россия Баш дәүләт энергия күзәтчелеге идарәсенең тикшереп торучы параметрларыннан гайре) срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

1.2. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төрдәге техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе (алга таба – Идарә) дәүләт вазыйфасын башкаручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы була.

Идарәнең территориаль бүлекчәләре, Идарәнең күзәтчелек һәм автоматлаштырып исәпкә алу бүлеге (алга таба – Идарә бүлекчәсе, Идарә бүлекчәләре), Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелеге идарәсенең баш дәүләт инженер-инспекторы, Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелеге идарәсенең баш дәүләт инженер-инспекторы урынбасары, Дәүләт техник күзәтчелеге идарәсенең Татарстан Республикасы шәһәрләренең, районнарының баш дәүләт инженер-инспекторлары дәүләт вазыйфасын турыдан-туры башкаручылар була.

Дәүләт вазыйфасы турыдан-туры Идарә башлыгы, башлык урынбасары боерыгы белән тикшерүләр уздыруга вәкаләт тапшырылган Идарәнең вазыйфаи затлары (алга таба – вазыйфаи затлар) тарафыннан башкарыла.

Дәүләт вазыйфасын башкарганда вазыйфаи затлар прокуратура органнары, эксперт оешмалар, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар белән хезмәттәшлек итә.

1.3. Идарә тарафыннан дәүләт вазыйфасын башкару түбәндәге норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Конституциясе («Российская газета», № 237, 25.12.1993) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Граждан кодексы, 1994 елның 30 ноябре № 51-ФЗ, 1 өлеш (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 05.12.1994 № 32, ст. 3301) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы, 2001 елның 30 декабре № 195-ФЗ (алга таба – РФ КоАП) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 07.01.2002, № 1 (1 өлеш), ст.1) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге № 196-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 196-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 11.12.1995 № 50, ст.4873) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Техник җайга салу турында» 2002 елның 27 декабрендәге № 184-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 184-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 30.12.2002, № 52 (1 өлеш), ст.5140) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы № 59-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 59-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 08.05.2006, № 19, ст. 2060) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге № 294-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 294-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 29.12.2008 № 52 (1 өлеш), ст.6249) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 21 апрелендәге № 69-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 69-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 25.04.2011, № 17, ст.2310) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә үзйөрешле машиналарның һәм башка төрдәге техниканың техник торышына дәүләт күзәтчелеге турында» Россия Федерациясе Министрлар Советының – Хөкүмәтенең 1993 елның 13 декабрендәге № 1291 карары белән расланган Россия Федерациясендә үзйөрешле машиналарның һәм башка төрдәге техниканың техник торышына дәүләт күзәтчелеге турында нигезләмә («Россия Федерациясе Президенты

һәм Хөкүмәте актлары җыентыгы» 20.12.1993 № 51, ст. 4943) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә үзйөрешле машиналарга һәм башка төрдәге техникага паспортлар кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1995 елның 15 маендагы № 460 карары (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 22.05.1995 № 21, ст.1969) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 30 июнендәге № 489 карары белән расланган Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны планлы тикшерүләр уздыруның еллык планнарын дәүләт күзәтчелеге органнары һәм муниципаль тикшереп тору органнары тарафыннан әзерләү кагыйдәләре (алга таба – № 489 РФ Хөкүмәте карары) (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 12.07.2010 № 28, ст.3706) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Техник торышларына дәүләт күзәтчелеген башкаручы органнар тарафыннан теркәлгән үзйөрешле машиналарны һәм башка төрдәге техниканы техник карап чыгу турында» 2013 елның 13 ноябрендәге № 1013 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 25.11.2013 № 47, ст.6099) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары тарафыннан 16.01.1995 расланган Тракторларны, үзйөрешле юл салу һәм бүтән машиналарны һәм аларның тагылмаларын Россия Федерациясендә тракторларның, үзйөрешле юл салу һәм бүтән машиналарның һәм аларның тагылмаларының техник торышына дәүләт күзәтчелеге органнары тарафыннан дәүләт теркәве кагыйдәләре («Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлары бюллетене» № 5, 1995) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Нефть базаларын, ЯММ складларын, автомобильләргә ягулык салуның стационар һәм күчмә станцияләрен эксплуатацияләгәндә хезмәтне саклау буенча Россия Федерациясе Хезмәт министрлыгы тарафыннан 06.05.2002 № 33 расланган тармакара кагыйдәләр (алга таба – ПОТРМ-021-2002) («Российская газета» 11.06.2002 № 104);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законның нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 30.04.2009 № 141 боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы) («Российская газета» № 85, 14.05.2009) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Дәүләт тармак стандартлары:

ГОСТ 12.2.042-2013 «Дәүләтара стандарт. Хезмәт иминлеге стандартлары системасы. Терлекчелек һәм терлек азыгы җитештерү өчен машиналар һәм технологик җайланмалар. Иминлекнең гомуми таләпләре» Росстандартның 08.11.2013 № 1381-ст боерыгы белән расланган (М.: Стандартинформ, 2014);

ГОСТ 12.2.003-91 «Хезмәт иминлеге стандартлары системасы. Житештерү җайланмалары. Иминлекнең гомуми таләпләре» СССР Госстандартының 06.06.1991 № 807 карары белән расланган (М.: Издательство стандартов, 1991);

ГОСТ 12.2.007.0-75 «Хезмәт иминлеге стандартлары системасы. Электротехник эшләнмәләр. Иминлекнең гомуми таләпләре» СССР Госстандартның 10.09.1975 № 2368 карары белән гамәлгә кертелгән (М.: ИПК Издательство стандартов, 2001);

ГОСТ 7463-2003 «Тракторлар һәм авыл хуҗалыгы машиналары өчен пневматик шиналар» Стандартлаштыру, метрология һәм сертификацияләү буенча Дәүләтара Совет тарафыннан расланган (МГС) (М.: ИПК Издательство стандартов, 2004);

ГОСТ Р 53489-2009 ССБТ «Элмәле һәм тагылмалы авыл хуҗалыгы машиналары. Иминлекнең гомуми таләпләре» Федераль техник җайга салу һәм метрология агентлыгының 10.12.2009 № 678-ст боерыгы белән расланган (М.: Стандартинформ, 2010);

ГОСТ 7751-2009 «Авыл хуҗалыгында кулланылучы техника. Саклау кагыйдәләре» Федераль техник җайга салу һәм метрология агентлыгының 04.03.2011 № 27-ст боерыгы белән расланган (М.: Стандартинформ, 2011);

ГОСТ Р 50911-96 «Авыл хуҗалыгы техникасы. Ремонт-технологик җайланмалар. Иминлекнең гомуми таләпләре» Россия Госстандартның 06.06.1996 № 354 карары белән кабул ителгән һәм гамәлгә кертелгән (М.: ИПК Издательство стандартов, 1996);

ГОСТ Р 12.4.026-2001 ССБТ «Сигнал төсләре, иминлек тамгалары һәм сигнал билгеләүләр» Россия Госстандартның 19.09.2001 № 387-ст карары белән кабул ителгән һәм гамәлгә кертелгән (М.: ИПК Издательство стандартов, 2005);

ГОСТ 12.0.004-90 «Дәүләтара стандарт. Хезмәт иминлеге стандартлары системасы. Хезмәт иминлегенә укытуны оештыру. Гомуми нигезләмәләр» СССР Госстандартның 05.11.1990 № 2797 карары белән расланган һәм гамәлгә кертелгән (М.: Издательство стандартов, 2001);

ГОСТ 12.1.030-81. Хезмәт иминлеге стандартлары системасы. Электр иминлеге. Саклану өчен җиргә тоташтыру. Нульләштерү» (СССР Госстандартның 15.05.1981 № 2404 карары белән расланган) (01.03.1987 ред.);

ГОСТ 1510-84. Нефть һәм нефть продуктлары. Маркировкалау, төргәкләү, транспортлау һәм саклау» (СССР Госстандартның 07.08.1984 № 2776 карары белән расланган) (01.01.1991 ред.);

«Татарстан Республикасында үзйөрешле машиналарның һәм башка төрдәге техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 26.12.2011 № 1064 карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыелмасы» 03.02.2012, № 9, ст.0321) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт вазыйфаларын башкаруның административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.12.2012 № 1192 карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыелмасы» 25.01.2013, № 7, ст.0194) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.4. Дәүләт күзәтчелеге предметы – агросәнәгать комплексында машиналар һәм җайланмалар милекчеләре булган юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар, йә милекчеләр исеменнән эш йөртүче, шушы машиналардан һәм җайланмалардан файдаланучы яисә алар белән эш итүче затлар (алга таба – машиналар һәм җайланмалар хуҗалары) тарафыннан кешеләр гомере, сәламәтлеге һәм мөлкәте иминлеген, әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итү өлешендә машиналарны һәм җайланмаларны эксплуатацияләү өлкәсендә Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән мәҗбүри кагыйдәләрне үтәүне тикшерү (Россия Дәүләт техник күзәтчелеге идарәсенең һәм Россия Баш дәүләт энергия күзәтчелеге идарәсенең тикшереп торучы параметрларыннан гайре) (алга таба – Мәҗбүри таләпләр).

Күзәтчелек объектлары булган машиналар һәм җайланмалар (үзйөрешле машиналар һәм башка төрдәге техника) (алга таба – машиналар һәм җайланмалар) төрләре исемлеге әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтада китерелә.

1.5. Дәүләт күзәтчелеген башкарганда вазыйфаи затларның хокуклары һәм бурычлары

1.5.1. Идарә башлыгы, башлык урынбасары боерыгы белән тикшерүләр уздыру вәкаләтләре тапшырылган Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторлары (алга таба – баш дәүләт инженер-инспекторлары) дәүләт күзәтчелеген башкарганда түбәндәге хокукларга ия:

кешеләр гомере, сәламәтлеге, мөлкәт сакланышы, әйләнә-тирә мохитне саклау өчен иминлек тәэмин итү өлкәсендә Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләр, шулай ук стандартлар, норматив документлар белән регламентлана торган кагыйдәләрне үтәүне тикшерергә (Россия Дәүләт техник күзәтчелеге идарәсенең һәм Россия Баш дәүләт энергия күзәтчелеге идарәсенең тикшереп торучы параметрларыннан гайре);

тикшерүләр нәтиҗәләре буенча актлар төзергә, актлар белән юридик затны, индивидуаль эшкуарны таныштыру өчен аларны тапшырырга;

юридик затка, индивидуаль эшкуарга, ачыкланган хокук бозуларны бетерү срокларын күрсәтеп, аларны бетерү турында һәм (яисә) кешеләр гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларына, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкярләргә), дәүләт иминлегенә, физик затлар һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә зарар китерүне кисәтү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш

хәлләр барлыкка килүне кисәтү чараларын, шулай ук федераль законнарда каралган чараларны уздыру турында күрсәтмәләр (алга таба – күрсәтмәләр) бирергә;

административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә һәм административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча эшләр алып баруда катнашырга;

оешмалар житәкчеләре белән килештереп, дәүләт күзәтчелеген башкаруга, машиналарның һәм җайланмаларның техник торышын бәяләүгә һәм Идарәнең башка вазыйфаларына бәйле эшләр алып бару өчен белгечләр җәлеп итәргә;

техник торышы әйләнә-тирә мохитне саклау таләпләренә туры килми торган яисә иминлек таләпләренә җавап бирми торган күзәтчелектәге үзйөрешле машиналарны һәм башка төрдәге техниканы эксплуатацияләүне тыярга;

дәүләт техник күзәтчелеге органнары компетенциясенә керүче һәм мондый карарлар кабул итү хокукына ия булган органнарның (оешмаларның) өстәмә хәл итүен таләп итүче мәсьәләләр буенча ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында һичшиксез каралырга тиешле күрсәтмәләр җибәрергә;

оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан Идарә күзәтчелегендәге машиналарны һәм җайланмаларны эксплуатацияләү кагыйдәләрен һәм нормаларын үтәүләре турындагы белешмәләрне, ә мәҗбүри рәвештә иминләштерелергә тиешле күзәтчелектәге транспорт чаралары буенча белешмәләрне, шулай ук мәҗбүри иминләштерү шартнамәләре турындагы белешмәләрне, мәҗбүри иминләштерү буенча статистик һәм бүтән белешмәләрне соратып алырга.

1.5.2. Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторлары дәүләт күзәтчелеген башкарганда түбәндәге бурычларны үтәргә тиеш:

Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау буенча тапшырылган вәкаләтләрен үз вакытында һәм тулысынча үтәргә;

Россия Федерациясе законнарын, тикшерү уздырыла торган юридик затның, индивидуаль эшкуарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

Идарә башлыгының, башлыгы урынбасарының тикшерү уздыру турындагы боерыгы нигезендә тикшерү уздырырга;

хезмәт вазыйфаларын үтәгән вакытта гына тикшерү уздырырга, күчмә тикшерүне хезмәт таныклыгын, Идарә башлыгының, башлыгы урынбасарының тикшерү билгеләү турындагы боерыгы күчермәсен күрсәткәндә генә һәм Идарәгә гражданнардан, шул исәптән юридик затлардан, индивидуаль эшкуарлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкярләргә), дәүләт

иминлегенә куркыныч тудыру, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр тудыру (гадәттән тыш хәлләр янау) фактлары турында мәгълүмат кергәндә, тикшерү уздыру турындагы документ күчермәсе нигезендә генә уздырырга;

юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү уздырганда каршылык күрсәтмәскә һәм тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

юридик затның җитәкчесен, бүтән вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен, индивидуаль эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга;

ачыкланган хокук бозулар фактлары буенча күрелүче чараларны билгеләгәндә әлеге чараларның хокук бозулар авырлыгына туры килү-килмәвен, аларның кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкярләргә), дәүләт иминлегенә куркыныч тудыру, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр тудыру мөмкинлекләрен исәпкә алырга, шулай ук гражданнарның, шул исәптән юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезсез чикләүне булдырмаска;

юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар гамәлләренә карата шикаять белдергәндә Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә аларның нигезсезлеген исбатларга;

№ 294-ФЗ Федераль законы белән билгеләнгән тикшерү срокларын үтәргә;

юридик заттан, индивидуаль эшкуардан Россия Федерациясе законнары белән каралмаган документларны һәм башка белешмәләрне бирүне таләп итмәскә;

күчмә тикшерү уздырыр алдыннан юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле соравы буенча аларны тикшерү уздыру өчен нигез булучы Административ регламент нигезләмәләре белән таныштырырга;

тикшерүләрне исәпкә алу журналында (булса) тикшерү уздыру турында язма ясарга.

1.5.3. Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторлары дәүләт күзәтчелеген башкарганда түбәндәгеләргә хокуксыз:

мәҗбүри таләпләр үтәлешен тикшерергә, әгәр мондый таләпләр исеменнән тикшерү уздырыла торган Идарә вәкаләтләренә карамаса;

СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән һәм Россия Федерациясе законнарына туры килмәүче таләпләрне үтәүне тикшерергә;

басылмаган хокукый актлар белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә тикшерергә;

планлы яисә планнан тыш тикшерү уздырганда юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, планлы яисә планнан тыш тикшерү уздырырга, моңа кешеләр гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларына, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкярләргә), дәүләт иминлегенә зарар китерү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү очрагы керми;

документлар, мәгълүмат, продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохитне тикшерү пробаларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын бирүне таләп итәргә, әгәр алар тикшерү объектлары булмаса яисә тикшерү предметына карамаса, шулай ук мондый документларның төп нөсхәләрен алырга;

продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын аларны тикшерүләр, сынап караулар, үлчәүләр өчен шушы үрнәкләрне, пробаларны билгеләнгән тәртиптә һәм үрнәкләрне, пробаларны алуның милли стандартлары, кагыйдәләре һәм аларны тикшерүләр, сынап караулар һәм үлчәүләр ысуллары, техник регламентлар яисә алар үз көчләренә кергәнче гамәлдә булган бүтән норматив техник документлар һәм тикшерүләр, сынап караулар һәм үлчәүләр кагыйдәләре һәм ысуллары белән билгеләнгән нормалардан артып киткән санда алу турында беркетмәләр төземичә генә алырга;

тикшерү нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция серен, хезмәт серен, бүтән закон белән саклана торган серне тәшкил итүче мәгълүматны алырга һәм таратырга, моңа Россия Федерациясе законнарында каралган очраклар керми;

тикшерү уздыруның билгеләнгән срокларыннан артып китәргә;

юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга алар исәбенә дәүләт күзәтчелеге чаралары уздыру турындагы күрсәтмәләр яисә тәкъдимнәр бирергә;

1.6. Үзләренә карата дәүләт күзәтчелеге чаралары уздырыла торган затлар түбәндәге хокукларга ия:

тикшерү уздырганда турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

Идарәдән, аның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына кагылышлы һәм бирүе федераль законнар белән каралган мәгълүмат алырга;

тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында үзенең тикшерү нәтиҗәләре белән танышуы, алар белән, шулай ук Идарәнең аерым вазыйфаи затлары гамәлләре белән килешүе яисә килешмәве турында күрсәтергә;

Идарәнең вазыйфаи затларының тикшерү уздырганда юридик затның, индивидуаль эшкуарның хокукларын бозуга китергән гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата административ тәртиптә һәм (яисә) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять белдерергә;

Эшкуарлар хокукларын яклау буенча Россия Федерациясе Президенты каршындагы вәкаләтле вәкилне йә Эшкуарлар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы вәкаләтле вәкилне җәлеп итәргә.

1.7. Үзләренә карата тикшереп тору чаралары уздырыла торган затларның бурычлары:

әгәр күчмә тикшерү уздыру алдыннан документар тикшерү уздырылмаган булса, Идарәнең күчмә тикшерү уздыру өчен җаваплы вазыйфаи затларына күчмә тикшерү уздыру максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле документлар белән танышу мөмкинлеге тудырырга;

Идарәнең күчмә тикшерү уздыручы вазыйфаи затларның һәм күчмә тикшерүдә катнашучы экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең тикшерелүче юридик зат, индивидуаль эшкуар эшчәнлеген башкарганда файдалана торган территориягә, биналарга, корылмаларга, төзелмәләргә, урыннарга, алар куллана торган үзйөрешле машиналарга һәм башка төрдәге техникага керү мөмкинлеген тәэмин итәргә.

1.8. Дәүләт вазыйфасын үтәү нәтиҗәсе түбәндәгеләр:

планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздырганда тикшерү нәтиҗәләре буенча акт (алга таба – тикшерү акты) (тикшерү уздыру турында актның типовой формасы РФ Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган);

мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган очракларда:

ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү һәм, бетерү срокларын күрсәтеп, аларны бетерү турында Дәүләт техник күзәтчелеге идарәсенең Татарстан Республикасы шәһәре, районы баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан имзаланган күрсәтмә (алга таба – күрсәтмә) (әлеге Регламентка 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча);

РФ КоАПта каралган административ хокук бозу турындагы беркетмә (әлеге Административ регламентка 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча);

административ хокук бозулар кылуга китерүче сәбәпләрне һәм шартларны бетерү турында күрсәтмә (кирәк булса).

## 2. ДӘҮЛӘТ ВАЗЫЙФАСЫН БАШКАРУ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР

2.1. Дәүләт вазыйфасын башкару турында мәгълүмат бирү тәртибе

2.1.1. Идарәнең урнашкан җире: 420111, Казан, Федосеевская ур., 36.

2.1.2. Идарәнең консультацияләр бирүче һәм турыдан-туры дәүләт вазыйфасын башкаручы бүлекләре урнашкан җире, телефоннары әлеге Административ регламентка 5 нче кушымтада китерелә.

2.1.3. Дәүләт вазыйфасын башкару мәсьәләләре буенча документлар һәм мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен почта адресы: 420111, Казан, Федосеевская ур., 36.

Идарә телефоннары: 8 (843) 221-77-85 – Идарәнең кабул итү бүлмәсе, 221-77-88 – Идарәнең күзәтчелек һәм автоматлаштырып исәпкә алу бүлеге.

Факсы: 8 (843) 221-77-85 – Идарәнең кабул итү бүлмәсе.

E-Mail: gostehnadzorrt@mail.ru

Әлеге Регламент «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Идарәнең рәсми сайтында урнаштырыла: http://gtn.tatarstan.ru.

2.1.4. Идарәнең һәм Идарә бүлекләре эшенең графигы:

Дүшәмбе - пәнҗешәмбе: 8.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр.

Җомга: 8.00 сәгатьтән алып 15.45 сәгатькә кадәр.

Ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

Төшке ашка тәнәфес: 12.00 сәгатьтән алып 12.45 сәгатькә кадәр.

2.1.5. Гражданнарны һәм юридик затларны кабул итү көн саен Идарә эше графигы нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.1.6. Дәүләт вазыйфасын башкару турында мәгълүмат түбәндәгечә бирелә:

турыдан-туры Идарә бүлекләрендә (шул исәптән документлар кабул итү өчен билгеләнгән урыннардагы махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән дә);

телефон элемтәсе чараларын кулланып;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән, шул исәптән «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә (http://uslugi.tatar.ru) (алга таба – Портал), массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару юлы белән дә.

2.1.7. Идарә бүлекләрендәге мәгълүмат стендларында түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла:

урнашкан җире, әлеге Административ регламентка 4 нче кушымтада күрсәтелгән контакт телефоннары турында белешмәләр, Идарәнең, Идарә бүлекләренең электрон почтасы адреслары, Идарәнең рәсми сайты адресы;

дәүләт вазыйфасын башкару эшчәнлеген җайга салучы закон һәм бүтән норматив хокукый актлардан өземтәләр;

машиналар һәм җайланмалар хуҗаларын Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторлары тарафыннан кабул итү режимы;

Идарәнең дәүләт вазыйфасын башкаручы баш дәүләт инженер-инспекторлары карарларына, гамәлләренә яисә гамәл кылмавына карата шикаять белдерү тәртибе.

2.1.8. Телефоннан шылтыратуларга һәм телдән мөрәҗәгатьләргә җавап биргәндә Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторлары мөрәҗәгать итүчеләрне кызыксындырган сораулар белән мөрәҗәгать итүчеләргә җентекләп һәм әдәпле итеп мәгълүмат бирәләр.

Телефон шылтыратуына җавап граждан шылтыраткан Идарә бүлегенең атамасы, Идарәнең телефонны алган баш дәүләт инженер-инспекторы

фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы турындагы мәгълүматтан башланырга тиеш.

2.1.9. Идарәнең телефонны алган баш дәүләт инженер-инспекторы мөрәҗәгать иткән гражданга куелган сорауларына мөстәкыйль рәвештә җавап бирә алмаганда кирәкле мәгълүмат алу мөмкин булган телефон номеры хәбәр итәлергә тиеш.

2.1.10. Дәүләт вазыйфасын башкаруга кагылышлы Идарәгә кергән язма мөрәҗәгатьләр язма мөрәҗәгать теркәлгән көннән 30 көнлек срокта карала.

2.1.11. Дәүләт вазыйфасын башкару барышы турында мәгълүмат бирү Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторлары тарафыннан шәхсән кабул иткәндә, почта, телефон элемтәсе, электрон почта аша гамәлгә ашырыла.

2.1.12. Консультацияләр шәхсән мөрәҗәгать иткәндә Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторларының кабул итү көннәрендә гомуми чират режимында бирелә, телефон, электрон почта (gostehnadzorrt@mail.ru), Идарәнең рәсми сайты (http://gtn.tatarstan.ru) аша мөрәҗәгать иткәндә шулар аша бирелә.

2.1.13. Әлеге Административ регламент белән каралган күләмдә консультацияләр һәм белешмәләр Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторлары тарафыннан дәүләт вазыйфасын башкаруның барлык срогы дәвамында эш вакытында бирелә. Барлык консультацияләр һәм белешмә мәгълүмат түләүсез бирелә.

2.1.14. Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторлары тарафыннан гражданнарны һәм оешмалар вәкилләрен кабул итү графигын бүлек башлыгы – Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы билгели һәм Идарә башлыгы тарафыннан раслана.

Идарәнең һәр баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан кабул итү вакыты атнасына кимендә 4 сәгать тәшкил итәргә тиеш.

Идарә аппаратында шәхсән кабул итү графигы әлеге Административ регламентка 5 нче кушымтада күрсәтелгән.

Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторлары тарафыннан шәхсән кабул итү графигы әлеге Административ регламентка 6 нчы кушымтада күрсәтелгән.

2.2. Юридик затлардан һәм индивидуаль эшкуарлардан дәүләт күзәтчелеге чараларын уздырган өчен түләү алуның рөхсәт ителмәве

Юридик затлардан һәм индивидуаль эшкуарлардан дәүләт күзәтчелеге чараларын уздырган өчен түләү алынмый, шул исәптән экспертлар һәм эксперт оешмаларын тикшерүләр уздыруга җәлеп иткән очракта да.

## 3. Дәүләт вазыйфасын башкару срогы

2.3.1. Һәр тикшерү срогы егерме эш көненнән артмаска тиеш.

2.3.2. Кече эшкуарлыкның бер үк субъектына карата планлы күчмә тикшерүләр уздыруның гомуми срогы елына кече предприятие өчен – илле сәгатьтән, микропредприятие өчен унбиш сәгатьтән артмаска тиеш.

2.3.3. Идарәнең күчмә планлы тикшерү уздыручы вазыйфаи затларының дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яисә) озакка сузыла торган тикшеренүләр, сынаулар, махсус экспертизалар һәм тикшерүләр уздыру зарурлыгына бәйле аерым очракларда, күчмә планлы тикшерү уздыру срогы Идарә башлыгы тарафыннан озайтылырга мөмкин, әмма бу срок егерме эш көненнән дә артмаска тиеш, кече предприятиеләргә карата – илле сәгатьтән, микропредприятиеләргә карата – унбиш сәгатьтән.

2.3.4. Россия Федерациясенең берничә субъектында үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик затка карата тикшерү уздыру срогы юридик затның һәр филиалы, вәкиллеге, аерымланган структур бүлекчәсе буенча аерым-аерым билгеләнә, бу чакта тикшерү уздыруның гомуми срогы алтмыш эш көненнән дә артмаска тиеш.

2.3.5. Планлы тикшерүләр өч елга бер мәртәбәдән дә ешрак уздырылмаска тиеш.

## 4. Тикшерүләр уздыру өчен нигезләр

2.4.1. Юридик затларны, индивидуаль эшкуарларны планлы тикшерүләр Идарә башлыгы боерыгы белән раслана торган планлы тикшерүләр уздыруның еллык планы (алга таба – еллык план) нигезендә гамәлгә ашырыла. Еллык планнар билгеләнгән тәртиптә әзерләнә һәм прокуратура органнары белән килештерелә.

Еллык план «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Идарәнең рәсми сайтында урнаштырыла.

2.4.2. Еллык планга планлы тикшерүне кертү өчен нигез түбәндәге көннән өч ел узу була:

1) юридик затны, индивидуаль эшкуарны дәүләт теркәвенә алганнан соң;

2) юридик затны, индивидуаль эшкуарны соңгы планлы тикшерү уздыру тәмамланганнан соң;

3) юридик зат, индивидуаль эшкуар Россия Федерациясе Хөкүмәте тиешле өлкәдә вәкаләт тапшырган федераль башкарма хакимияте органына кертелгән эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен башкаруны башлау турындагы хәбәрнамә нигезендә эшкуарлык эшчәнлеген башкара башлаганнан соң, эшләр башкару яисә хезмәтләр күрсәтү мондый хәбәрнамәләр тапшыруны таләп итсә.

2.4.3. Планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигез түбәндәгеләр була:

1) юридик затның, индивидуаль эшкуарның мәҗбүри таләпләрне бозу очракларын бетерү турында элек бирелгән күрсәтмәне үтәү срогы узу;

2) Идарәгә гражданнардан, шул исәптән индивидуаль эшкуарлардан, юридик затлардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә

органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан түбәндәге фактлар турында мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар керү:

а) кешеләр гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларына, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкярләргә), дәүләт иминлегенә зарар китерү куркынычы барлыкка килү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы туу;

б) кешеләр гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларына, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкярләргә), дәүләт иминлегенә зарар китерү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү;

в) кулланучылар хокукларын бозу (хокуклары бозылган гражданнар мөрәҗәгать иткәндә);

3) Идарә башлыгының Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте кушулары буенча һәм Прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнар үтәлешенә күзәтчелек кысаларында планнан тыш тикшерү уздыру турында Прокурор таләбе нигезендә чыгарылган боерыгы.

2.4.4. Юридик затларны, индивидуаль эшкуарларны планнан тыш күчмә тикшерү әлеге Административ регламентның 2.4.3 пунктындагы 2 пунктчасының «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча мондый юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органы белән килештереп уздырылырга мөмкин.

2.5. Дәүләт күзәтчелеген уздыруны турыдан-туры гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар

Дәүләт күзәтчелеге Идарә башлыгының, (башлыгы урынбасарының) боерыгы белән тикшерү уздыруга вәкаләт тапшырылган вазыйфаи затлары тарафыннан турыдан-туры гамәлгә ашырыла.

Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә, РФ КоАПның 8.22, 8.23 статьялары (Идарә күзәтчелегендәге техника өлешендә), 9.3 статьясы, 12.37 статьясы (Идарә күзәтчелегендәге техника өлешендә), 14.43 статьясы, 14.44 статьясы, 19.22 статьясының 1 өлеше (Идарә күзәтчелегендәге техника өлешендә), административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга хокуклы:

1) Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең баш дәүләт инженер-инспекторы, аның урынбасарлары;

2) Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Татарстан Республикасы шәһәрләренең һәм районнарының баш дәүләт инженер-инспекторлары.

РФ КоАПның 14.43 статьясындагы 3 өлеше, 19.4 статьясындагы 1 өлеше, 19.5 статьясындагы 1 һәм 5 өлешләре, 19.6, 19.7, 19.33 статьялары белән каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләрне

Идарәнең үз вәкаләтләре нигезендә дәүләт күзәтчелеген башкаручы вазыйфаи затлары хокуклы.

2.6. № 294-ФЗ Федераль законны бозган өчен юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның җаваплылыгы

1. Тикшерләр уздырганда юридик затлар, юридик затларның җитәкчеләре, бүтән вазыйфаи затлары яисә вәкаләтле вәкилләре шунда булуны тәэмин итәргә тиеш; индивидуаль эшкуарлар шунда булырга яисә мәҗбүри таләпләрне үтәү чараларын оештыру һәм уздыру өчен җаваплы вәкаләтле вәкилләренең шунда булуын тәэмин итәргә тиеш.

2. № 294-ФЗ Федераль законны бозуга китергән, нигезсез тикшерүләргә каршылык күрсәтүче, тикшерүләр уздырудан баш тартучы һәм (яисә) Идарәнең ачыкланган хокук бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрен билгеләнгән срокта үтәмәгән юридик затлар, аларның җитәкчеләре, бүтән вазыйфаи затлары яисә юридик затларның вәкаләтле вәкилләре, индивидуаль эшкуарлар, аларның вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

2.7. Идарәнең, аның вазыйфаи затларының тикшерү уздырганда җаваплылыгы

1. Идарә, аның вазыйфаи затлары тикшерү уздырганда вазыйфаларын, хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәгән, хокукка каршы гамәлләр кылган (гамәл кылмаган) очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

2. Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында мондый чаралар күрелгәннән соң ун көн эчендә Идарә хокуклары һәм (яисә) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, индивидуаль эшкуарга язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

3. Идарә Идарәнең вазыйфа затлары тарафыннан хезмәт бурычларын үтәүне тикшереп тора, вазыйфаи зат тарафыннан хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәүне исәпкә алып бара, тиешле хезмәт тикшерүләре уздыра һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый вазыйфаи затларга карата чаралар күрә.

## 3. ЮРИДИК ЗАТЛАРГА ҺӘМ ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАРЛАРГА КАРАТА БЕЛДЕРЕЛӘ ТОРГАН МӘҖБҮРИ ТАЛӘПЛӘР

Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга карата белдерелә торган һәм үтәлеше мәҗбүри таләпләр урнаштыра торган норматив хокукый актлар белән тикшереп торыла, аларның исемлеге 1 нче таблицада китерелә.

1 нче таблица

# ЮРИДИК ЗАТЛАРГА, ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАРЛАРГА КАРАТА БЕЛДЕРЕЛӘ ТОРГАН МӘҖБҮРИ ТАЛӘПЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

| Тикшереп тору объектлары (эшчәнлек төрләре, тикшереп тору төрләре) | Мәҗбүри таләпнең формулировкасы | Мәҗбүри таләпне урнаштыра торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. Машиналарга һәм җайланмаларга белдерелә торган таләпләр, шул исәптән: | | |
| 1. Игенчелек машиналары<br>2. Предприятиеләрнең эшкәртү цехларының машиналары һәм җайланмалары<br>3. Машиналарны ремонтлау һәм аларга техник хезмәт күрсәтү машиналары һәм җайланмалары<br>4. Терлекчелек фермалары машиналары һәм җайланмалары | 1. АХА составында гомуми файдаланудагы юлларда йөри ала торган һәм агрегатлаганда ЭС яктылык сигнализациясе приборларын яба торган машиналар үзләрнең яктылык сигнализациясе приборлары белән җиһазландырылырга тиеш. Яктылык сигнализациясе приборлары булуга һәм урнаштыруга карата таләпләр конкрет машиналарның ТУда билгеләнгән булырга тиеш. | ГОСТ Р 53489-2009 ССБТ (4.6.2 пункт) |
| | 2. Гомуми файдаланудагы юлларда хәрәкәттә катнашучы тагылмалар, ярымтагылмалар һәм яртылаш эленеп баручы машиналар эшче һәм туктап тору тормозлары һәм саклану чылбырлары (трослар) белән җиһазландырылырга тиеш. | ГОСТ Р 53489-2009 ССБТ (4.3.4 пункт) |
| 1.5. Нефть туплаучы һәм ягулык | 3. Тракторлар белән агрегатлана торган мобиль терлек азыгы өләшүче машиналар, агрегатлашуда өстәмә электергеч катнашуны таләп итми торган | ГОСТ 12.2.042-2013 (10.3.9 пункт) |

| | | |
|---|---|---|
| салучы җайланмалар | электргечләр һәм төеннәр белән тәэмин ителергә тиеш. | |
| | 4. Запарник-смесительләр һәм запарниклар герметизацияләнгән һәм 0,07 мПа максималь басымы белән эшләргә исәпләнгән булырга тиеш, бу чакта пар чыгу рөхсәт ителми. | ГОСТ 12.2.042-2013 (10.1.1 пункт) |
| | 5. Эшләмәгән чорында озак вакыт, кыска вакыт сакланырга тиешле машиналар һәм җайланмалар «Авыл хуҗалыгында кулланыла торган техника. Саклау кагыйдәләре» дәүләтара стандарт таләпләре нигезендә саклауга куелырга тиеш. | ГОСТ 7751-2009 (3, 6, 7, 8 бүлекләр) |
| | 6. Әйләнмәле киптерү барабаннары идәннән, мәйданчыктан кимендә 1000 мм биеклектәге култыксалар белән әйләндереп алынырга тиеш. Култыксалар барабанның тышкы контурыннан кимендә 1000 мм ераклыкта урнаштырыла. | ГОСТ 12.2.042-2013 (10.4.11 пункт) |
| | 7. Машиналарга техник хезмәт күрсәтү пунктлары ягулык-майлау материалларын һәм сөртү материалларын җыю өчен махсус тартма яисә әрҗәләр белән җиһазландырылырга тиеш. | ГОСТ 12.2.042-2013 (11.7 пункт) |
| | 8. Җайланмаларның хезмәткәрләрне яралау куркынычы булган үткен почмаклары, кырлары һәм кытыршы өслекләре булмаска тиеш. | ГОСТ 50911-96 (3.3 пункт) |

| | | |
|---|---|---|
| | 9. Эш урыны жирле вентиляция белән җиһазландырылырга тиеш. | ГОСТ 50911-96 (4.6.1 пункт) |
| | 10. Пульверизатор ярдәмендә әйберләрне буяу шкафларда, ябык урыннарда яисә идәнгә куелган камераларда башкарылырга һәм аларның жирле һава суырыткычы булырга тиеш. | ГОСТ 50911-96 (4.4.5 пункт) |
| | 11. Үткенләгеч һәм өслеген чистарту-ялтырату өчен билгеләнгән җайланмалар жирле тузан суырткыч белән тәэмин ителергә тиеш, суырткычның саклау экраны блогына беркетелгән һәм эшкәртелгән материаллар өчен бушаткычы булган эшләтеп җибәрү җайланмасы булырга тиеш. | ГОСТ Р 50911-96 (4.7.2 пункт) |
| | 12. Җайланманың барлык хәрәкәтчән һәм әйләнмәле өлешләре киртәләнгән булырга яисә хезмәт күрсәтүче персонал яраланмаслык итеп урнаштырылган булырга тиеш. Саклау киртәләре – ГОСТ 12.2.062 буенча. | ГОСТ Р 50911-96 (6.1 пункт) |
| | 13. Киртәләрнен, саклану җайланмаларының өслекләре, шулай ук җайланмаларның эшләүчеләр өчен куркыныч тудырырлык башка өлешләрендә «Сигнал төсләр, иминлек тамгалары һәм сигнал билгеләүләр» РФ дәүләт стандарты таләпләре нигезендә иминлек тамгалары һәм сигнал төсләр булырга тиеш. | ГОСТ 12.4.026-2001 (5, 6 бүлекләр) |
| | 14. Күчмә яктырткычларны электр белән тәэмин итү жиргә тоташтырылган, аергыч трансформаторларга тоташтырылган 42 В егәрле махсус розеткалардан гамәлгә ашырылырга тиеш. | ГОСТ 12.2.042-2013 (6.8 пункт) |

| | | |
|---|---|---|
| | 15. Электр җайланмаларының кеше кагыла ала торган һәм электр иминлеген тәэмин итәрлек башка саклану төрләре булмаган метал өлешләре саклану яисә нульләштерү өчен җиргә тоташтырылырга тиеш. | ГОСТ 12.1.030-81 (1.2 пункт) |
| | 16. Электр көче зур булган щитлар, шкафлар, әрҗәләр һәм терлекләр, кош-корт урнаштырылган яисә терлек азыгы яңадан эшкәртелә торган биналарда урнаштырылган машиналарга идарә итү пультлары аерым бүлмәләрдә яисә кабиналарда | ГОСТ 12.2.042-2013 (6.18 пункт) |
| | 17. Нефть һәм нефть продуктларының һәр маркасын атмосфера явым-төшемнәре һәм тузан әләкмәслек аерым резервуарларда сакларга кирәк. | ГОСТ 1510-84 (4.5 пункт) |
| | 18. Метал резервуарлар, предприятиеләрнең озак саклана торган резервуарларыннан гайре, даими рәвештә чистартып торылырга тиеш:<br>кимендә елына бер мәртәбә – майлау материалларына утырмалар һәм майлы утырмалар өчен;<br>кимендә ике елга бер мәртәбә – калган майлар, автомобиль бензиннары, дизель ягулыклары, парафиннар һәм физик-химик үзенчәлекләре буенча шундый нефть продуктлары өчен.<br>Нефть, мазутлар, мотор ягулыклары һәм физик-химик үзенчәлекләре буенча шундый нефть продуктлары саклана торган метал һәм тимер-бетон резервуарлар кирәк булуына карап сакланырга тиеш, саклау шартлары аларның сыйфатына, резервуарларның ышанычлы саклау дәрәҗәсенә карап билгеләнә. Резервуарларда җыелган су һәм пычраулар | ГОСТ 1510-84 (4.6 пункт) |

| | | |
|---|---|---|
| | елына кимендә бер мәртәбә чистартылырга тиеш. | |
| 2. Машиналарның һәм җайланмаларның аерым механизмнары | «Техник торышларына дәүләт күзәтчелеген башкаручы органнар тарафыннан теркәлгән үзйөрешле машиналарны һәм башка төрдәге техниканы техник карап чыгуны уздыру кагыйдәләре» нигезендә техник карап чыгуны уздырганда аерым төр машиналарга карата белдерелә торган таләпләр күләмендә белдерелә (параметрларны да кертеп). | «Техник торышларына дәүләт күзәтчелеген башкаручы органнар тарафыннан теркәлгән үзйөрешле машиналарны һәм башка төрдәге техниканы техник карап чыгуны уздыру турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 13 ноябрендәге № 1013 карарына кушымта |

## 5. ТИКШЕРҮ УЗДЫРГАНДА ЮРИДИК ЗАТ, ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАР ТАРАФЫННАН ТАПШЫРЫЛА ТОРГАН ДОКУМЕНТЛАР

Тикшерү уздыру максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге, шулай ук мондый документлар формаларын билгели торган норматив хокукый актлар 2 нче таблицада китерелә.

2 нче таблица

### ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ МАКСАТЛАРЫНА ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫНА ИРЕШҮ ӨЧЕН ЮРИДИК ЗАТ, ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАР ТАРАФЫННАН ТАПШЫРЫЛА ТОРГАН ДОКУМЕНТЛАР ИСЕМЛЕГЕ

| Тикшерү уздыру өчен тапшырыла торган документ | Документ формасын билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|
| 1. Юридик затның йә индивидуаль эшкуарның гамәлгә кую һәм теркәү документлары | «Юридик затларны, индивидуаль эшкуарларны һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларын дәүләт теркәвенә алганда теркәүче органга тапшырыла торган документлар рәвешләрен һәм аларны рәсмиләштерүгә карата таләпләрне раслау турында» Федераль салым хезмәтенең 25.01.2012 № ММВ-7-6/25@ боерыгы |
| 2. Гражданның шәхесен таныклаучы документлар (индивидуаль эшкуар өчен) | «Россия Федерациясе гражданы паспорты турындагы нигезләмәне, Россия Федерациясе гражданы паспорты бланкы үрнәген һәм тасвирламасын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1997 елның 8 июлендәге № 828 карары |
| 3. Ышанычнамә (юридик зат, индивидуаль эшкуар мәнфәгатьләрен белдерүче зат вәкаләтләрен раслый торган документлар) | Россия Федерациясе Граждан кодексы |
| 4. Паспортлар, машиналар һәм җайланмаларны эксплуатацияләү инструкциясе | Үзйөрешле машиналар һәм башка төрдәге техника паспорты турында 26.06.1995 № 318 Россия Федерациясе Дәүләт стандарты белән расланган нигезләмә |
| 5. Машиналарның һәм җайланмаларның исәпкә алу-теркәү документлары | Тракторларны, үзйөрешле юл салу һәм бүтән машиналарны һәм аларның тагылмаларын Россия Федерациясендә дәүләт теркәвенә алу буенча Россия Федерациясе Министрлар Советының 1993 елның 13 декабрендәге № 1291 карары белән расланган кагыйдәләре үзйөрешле машиналарның һәм башка төрдәге техниканың техник торышына дәүләт күзәтчелеге органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла. |

| | |
|---|---|
| 6. Юридик затны, индивидуаль эшкуарны дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан уздырла торган тикшерүләрне исәпкә алу журналы | Россия Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы |

## 5. АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫҢ (ГАМӘЛЛӘРНЕҢ) СОСТАВЫ, ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ, АЛАРНЫ ҮТӘҮ СРОКЛАРЫ, АЛАРНЫ ҮТӘҮГӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР, ШУЛ ИСӘПТӘН АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫ (ГАМӘЛЛӘРНЕ) ЭЛЕКТРОН РӘВЕШТӘ ҮТӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

5.1. Дәүләт вазыйфасын башкарганда административ процедуралар составы

Дәүләт күзәтчелеге планлы һәм планнан тыш күчмә тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Дәүләт вазыйфасын башкаруга түбәндәге административ процедуралар керә:

тикшерү уздыруны планлаштыру;

тикшерү уздыруга әзерләнү;

планлы күчмә тикшерү уздыру;

планнан тыш күчмә тикшерү уздыру;

тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

тикшерү уздырганда ачыкланган хокук бозулар фактларына карата Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторлары тарафыннан күрелә торган чаралар.

Дәүләт вазыйфасын үтәүнең блок-схемасы әлеге Административ регламентка 7 нче кушымтада китерелә.

5.2. «Тикшерүләр уздыруны планлаштыру» административ процедурасы

5.2.1. Еллык планны әзерләү сроклары җитү «Тикшерүләр уздыруны планлаштыру» административ процедурасын башлау өчен нигез була.

5.2.2. Тикшерүләр уздыруны планлаштыру өчен җаваплы вазыйфаи зат Идарә башлыгы урынбасары була. Тикшерүләр уздыруның еллык планын төзү өчен җаваплы вазыйфаи зат Идарәнең күзәтчелек һәм автоматлаштырып исәпкә алу бүлеге башлыгы була.

5.2.3. Еллык планда түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1. эшчәнлекләре планлы рәвештә тикшерелергә тиешле юридик затларның (аларның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) атамасы, индивидуаль эшкуарларның фамилияләре, исемнәре, атасы исемнәре, юридик затлар (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) урнашкан җирләр яисә индивидуаль эшкуарлар тарафыннан фактта эшчәнлек алып бару урыннары;
2. һәр планлы тикшерүне уздыру максаты һәм нигезе;
3. һәр планлы тикшерү уздыруны башлау датасы һәм сроклары;
4. конкрет планлы тикшерүне башкаручы Идарә атамасы. Идарә муниципаль контроль органнары белән бергәләп планлы тикшерү уздырганда мондый тикшерүдә катнашучы барлык органнар атамасы күрсәтелә.

5.2.4. Еллык план Идарә бүлекләре тарафыннан күзәтчелек һәм автоматлаштырып исәпкә алу бүлекләренә җибәрелә торган белешмәләр нигезендә формалаштырыла.

5.2.5. Планны төзү даимилеге – ел саен.

5.2.6. Еллык план Идарәнең күзәтчелек һәм автоматлаштырып исәпкә алу бүлеге тарафыннан формалаштырыла.

5.2.7. Еллык планны эшләү сроклары җиткәндә күзәтчелек һәм автоматлаштырып исәпкә алу бүлеге башлыгы еллык план проектын әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи затны билгеләп куя.

Үтәлү срогы: планлы тикшерүләр уздыру елы алдыннан килүче елның 1 августыннан да соңга калмыйча.

5.2.8. Еллык план проектын әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат еллык план проектын әзерләү турында Идарә башлыгы боерыгы проектын рәсмиләштерә һәм аны Идарә башлыгы имзалавына җибәрә.

Үтәлү срогы: еллык план проектын әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат билгеләп куелган көннән соң килүче бер эш көне эчендә.

5.2.9. Еллык план проектын әзерләү турындагы боерыкны Идарә башлыгы имзалаганнан соң еллык план проектын әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша электрон документ рәвешендә Идарә бүлекләренә җибәрә.

Үтәлү срогы: боерыкка имза салынган көннән соң килүче бер эш көне эчендә.

5.2.10. Идарә бүлекләре машиналар һәм җайланмалар хуҗалары турындагы белешмәләрне әлеге Административ регламентның 5.2.3 пунктындагы 1 пунктча нигезендә еллык план проектын әзерләү турындагы боерыкта күрсәтелгән срокта еллык план проектына кертү өчен аларны Идарәнең күзәтчелек һәм автоматлаштырып исәпкә алу бүлегенә җибәрә.

Үтәлү срогы: планлы тикшерүләр уздыру елыннан алдагы елның 20 августыннан да соңга калмыйча.

5.2.11. Әлеге Административ регламентның 5.2.10 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне алганнан соң еллык план проектын әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат алынган белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең ЕГРЮЛ, ЕГРИП алынган ачык һәм һәркем өчен алу мөмкинлеге булган белешмәләр базасы ярдәмендә тикшерә, шулай ук планлы тикшерүне еллык план проектына кертү нигезләрен әлеге Административ регламентның 2.4.2 пункты нигезендә тикшерә.

Үтәлү срогы: планлы тикшерүләр уздыру елыннан алдагы елның 25 августыннан да соңга калмыйча.

5.2.12. Юридик затны, индивидуаль эшкуарны еллык план проектына кертү өчен нигезләр булмаган очракта, еллык план проектын әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат юридик затны, индивидуаль эшкуарны еллык план проектыннан төшереп калдыра.

Юридик зат, индивидуаль эшкуар еллык план проектын әзерләү өчен кирәкле белешмәләрне (мәгълүматны) тапшырмаган яисә үз вакытында тапшырмаган йә мондый белешмәләрне (мәгълүматны) тулы күләмдә тапшырмаган яисә дөрес булмаган килеш тапшырган очракта, юридик затка, индивидуаль эшкуарга карата РФ КоАПның 19.7 статьясы буенча РФ КоАПта каралган тәртиптә административ хокук бозулар турында эш кузгатыла.

5.2.13. Еллык план проектын әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат еллык план проектын күзәтчелек һәм автоматлаштырып исәпкә алу бүлеге башлыгы, Идарә башлыгы белән килештерә, аннары аны планлы тикшерүләр уздыру планлаштырыла торган машиналар һәм җайланмалар хуҗалары урнашкан урын буенча прокуратура органына килештерү өчен җибәрә.

Үтәлү срогы: планлы тикшерүләр уздыру елыннан алдагы елның 1 сентябренә кадәр.

5.2.14. Еллык план проектын карау нәтиҗәләре буенча кергән прокуратура органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып төзәтелгән еллык план проекты Идарә башлыгына раслауга еллык план проектын әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат тапшыра.

Үтәлү срогы: прокуратура тәкъдимнәре белән бергә еллык план проекты кергән көннән соң килүче биш эш көне эчендә.

5.2.15. Еллык план проектын раслау турында Идарә башлыгы тарафыннан карар кабул итү критерийлары:

әлеге Административ регламентның 5.2.3 пунктында күрсәтелгән мәгълүматның еллык план проектында булуы;

планлы тикшерүләр уздыруның еллык планына әлеге Административ регламентның 2.4.2 пункты нигезендә планлы тикшерүне кертү өчен нигезләр булу;

еллык план проектын формасының Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 489 карарында каралган формасына туры килүе.

5.2.16. Еллык план проектын әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат расланган еллык планны кәгазь саклагычта (электрон рәвештәге күчермәсен кушып) тиешле прокуратура органына тапшырылуы турындагы хәбәрнамәсе белән, заказлы почта юлламасы рәвешендә йә электрон имза салынган электрон документ рәвешендә җибәрә.

Үтәлү срогы: планлы тикшерүләр уздыру елыннан алдагы елның 1 ноябренә кадәр.

5.2.17. Еллык план проектын әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат расланган еллык планны Идарәнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны оештыра.

Үтәлү срогы: планлы тикшерүләр уздыру елыннан алдагы елның 31 декабренә кадәр.

5.2.18. «Тикшерүләр уздыруны планлаштыру» административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе расланган еллык план була.

## 5.3. «Тикшерүләр уздыруны планлаштыру» административ процедурасы

5.3.1. Еллык план нигезендә планлы күчмә тикшерү уздыру сроклары җитү «Тикшерүләр уздыруны планлаштыру» административ процедурасын башлау өчен нигез була.

5.3.2. Еллык план нигезендә планлы күчмә тикшерү уздыру сроклары җиткәндә Идарәнең күзәтчелек һәм автоматлаштырып исәпкә алу бүлеге башлыгы планлы күчмә тикшерү уздыру турындагы боерыкны әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи затны билгеләп куя (алга таба тиешенчә – боерыкны әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат, боерык).

Үтәлү срогы: тикшерү уздыру башланырга 6 эш көненнән дә соңга калмыйча.

5.3.3. Боерыкны әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

юридик затны, индивидуаль эшкуарны планлы күчмә тикшерү уздыру турындагы боерык проектын әзерли (планлы күчмә тикшерү уздыру турындагы боерыкның типовой формасы РФ Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган);

планлы күчмә тикшерү уздыру турындагы боерык проектын Идарәнең күзәтчелек һәм автоматлаштырып исәпкә алу бүлеге башлыгына, аннары Идарә башлыгы урынбасарына һәм имзалау өчен Идарә башлыгына йә Идарә башлыгы урынбасарына җибәрә.

Боерыкта планлы күчмә тикшерү уздыру өчен җаваплы вазыйфаи зат – Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы – Идарә инспекторы күрсәтелә.

Үтәлү срогы: планлы күчмә тикшерү уздыру башланырга кимендә 5 эш көне кала.

5.3.4. Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы – Идарә инспекторы планлы күчмә тикшерү уздыру турында юридик затка, индивидуаль эшкуарга планлы күчмә тикшерү уздыру хакындагы боерык күчермәсен, тапшырылуы турындагы хәбәрнамәсе белән, заказлы почта юлламасы рәвешендә яисә бүтән ысулда җибәрү юлы белән хәбәр итә.

Үтәлү срогы: планлы күчмә тикшерү уздыру башланырга өч эш көненнән дә коңга калмыйча.

5.3.5. Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы – Идарә инспекторы планнан тыш күчмә тикшерү уздыру турында юридик затка, индивидуаль

эшкуарга мөмкин булган теләсә нинди ысул белән хәбәр итә, моңа әлеге Административ регламентның 2.4.3 пунктындагы 2 пунктчасында планнан тыш күчмә тикшерү уздыру нигезләре күрсәтелгән планнан тыш күчмә тикшерү керми.

Үтәлү срогы: планнан тыш күчмә тикшерү уздыру башланырга кимендә егерме дүрт сәгать кала.

5.3.6. Планнан тыш күчмә тикшерү уздыру өчен әлеге Административ регламентның 2.4.3 пунктындагы 2 пунктчасының «а» и «б» пунктчалары нигез булган очракта, Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы – Идарә инспекторы:

юридик затның, индивидуаль эшкуарның эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органына планнан тыш күчмә тикшерү уздыруны килештерү турында гариза әзерли, гаризаны Идарә башлыгы белән килештерә, аңа Идарә башлыгы (башлыгы урынбасары) тарафыннан иза салдыра (планнан тыш күчмә тикшерү уздыруны прокуратура органы белән килештерү турындагы гаризаның типовой формасы РФ Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган);

гаризаны прокуратура органына кулдан, тапшырылуы турындагы хәбәрнамә белән, заказлы почта юлламасы рәвешендә, яисә, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза салынган килеш, электрон документ рәвешендә җибәрә. Гаризага планнан тыш күчмә тикшерү уздыру турында Идарә башлыгы (башлыгы урынбасары) боерыгы күчермәсе һәм аны уздыру өчен нигез булган белешмәләре кергән документлар кушып бирелә.

Үтәлү срогы: планнан тыш күчмә тикшерү уздыру турында боерык имзаланган көн.

5.3.7. Идарәнең дәүләт күзәтчелеге чараларын уздыруга тикшерелү уздырыла торган юридик затларларга, индивидуаль эшкуарларга карата граждан-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелүче затларның аффилиацияләнгән затлары булмаган экспертларны, эксперт оешмаларын Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә мөмкин.

5.3.8. «Тикшерү уздыруга әзерлек» административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе түбәндәгеләр була:

боерык;

тикшерү уздыру турында юридик зат, индивидуаль эшкуар адресына җибәрелгән хәбәрнамә (боерык күчермәсе);

законнарда каралган очракларда – планнан тыш күчмә тикшерү уздыруны прокуратура белән килештерү турында гариза.

## 5.4. «Планлы күчмә тикшерү уздыру» административ процедурасы

5.4.1. Планлы күчмә тикшерү уздыруны башлау өчен Идарә башлыгының, (башлыгы урынбасарының) планлы күчмә тикшерү уздыру турындагы боерыгы нигез була.

5.4.2. Планлы күчмә тикшерү уздыру предметы – юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан эшчәнлек башкарганда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәү, шулай ук эшкуарлык эшчәнлегенең билгеле бер төрләрен башкаруны башлау турындагы хәбәрнамәнең мәҗбүри таләпләргә туры килүе.

5.4.3. Юридик затны, индивидуаль эшкуарны тикшерә башлаганчы Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы юридик зат, индивидуаль эшкуар файдалана торган һәм тикшерелергә тиешле машиналарны һәм җайланмаларны имин эксплуатацияләүнең гамәлдәге стандартларын, инструкцияләрен, таяланмаларын өйрәнә. Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы, мәҗбүри таләпләрне бозуларның моңарчы ачылганнарын бетерү чараларының нәтиҗәлелеген тикшерү максатында аларны ачыклауга игътибар итеп, барлык алдагы тикшерүләрнең материалларын анализлый.

5.4.4. Планлы күчмә тикшерү уздыру көнендә Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы юридик зат урнашкан урынга, индивидуаль эшкуар эшчәнлек башкаручы урынга һәм (яисә) алар үз эшчәнлекләрен фактта алып бара торган урынга бара.

5.4.5. Планлы күчмә тикшерү Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторының хезмәт таныклыгын күрсәтүдән, юридик затның җитәкчесен, бүтән вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен, индивидуаль эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен планлы күчмә тикшерү билгеләү турында Идарә башлыгының, (башлыгы урынбасарының) боерыгы, шулай ук планлы күчмә тикшерү уздыру максатлары, бурычлары, нигезләре, тикшереп тору чаралары төрләре һәм күләмнәре белән, планлы күчмә тикшерүгә җәлеп ителүче экспертлар составы, эксперт оешмалар вәкилләре, аны уздыру сроклары һәм шартлары белән һичшиксез таныштырудан башлана.

Идарә башлыгының, (башлыгы урынбасарының) боерыгының мөһер белән таныкланган күчермәсе, Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы – Идарә инспекторы имзасын куйдырып, юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тапшырыла.

Тикшерелергә тиешле затлар таләбе буенча Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы – Идарә инспекторы Идарә турында, шулай ук, тикшерүдә катнашкан очракта, экспертлар, эксперт оешмалары турында мәгълүмат бирергә тиеш.

5.4.6. Юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторына – Идарә инспекторына күчмә тикшерү максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле документлар белән танышу мөмкинлеген тудырырга, шулай ук күчмә тикшерү уздыручы Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторының – Идарә инспекторының һәм күчмә тикшерүдә катнашучы экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең территориягә керә алуын, эшчәнлек башкарганда юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан файдаланыла торган машиналарга һәм җайланмаларга, биналарга, корылмаларга, төзелмәләргә, бүлмәләргә,

жайланмаларга, шундый объектларга, транспорт чараларына керә алуын тәэмин итәргә тиеш.

5.4.7. Планлы күчмә тикшерү барышында Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы – Идарә инспекторы түбәндәгеләрне тикшерә:

дәүләт техник күзәтчелеге органнары тарафыннан теркәлүче машиналарны;

дәүләт техник күзәтчелеге органнарында теркәлмәгән машиналарны һәм жайланмаларны.

Дәүләт техник күзәтчелеге органнары тарафыннан теркәлүче машиналар параметрлары буенча һәм техник карау күләмендә тикшерелә.

Машиналар һәм жайланмалар ремонты сыйфатын сайлап алып тикшергәндә хуҗалары һәм сервис предприятиеләре ремонтлый торган машиналар һәм жайланмалар тикшерелә.

Машиналарга һәм жайланмаларга техник хезмәт күрсәтүнең кагыйдәләрен үтәүне сайлап алып тикшергәндә хуҗалары һәм сервис предприятиеләре хезмәт күрсәтә торган машиналар һәм жайланмалар тикшерелә.

Машиналарны һәм жайланмаларны саклауның стандартларын һәм бүтән техник документация белән билгеләнгән кагыйдәләрен үтәүне сайлап алып тикшергәндә машиналарның һәм жайланмаларның имин саклау стандартларына һәм башка нормалар таләпләренә туры килү-килмәве тикшерелә.

Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы – Идарә инспекторы тикшергәндә тикшерелгән машиналар һәм жайланмалар саны исәпкә алына, мәҗбүри таләпләрне бозулар теркәлеп куела. Ачыкланган барлык мәҗбүри таләпләрне бозуларга тикшерү барышында шунда булган затларның игътибары юнәлдерелә.

Күзәтчелек объектлары булган машиналар һәм жайланмалар төрләре әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтада китерелә.

5.4.8. Тикшерү уздыру срогы әлеге Административ регламентның 2.3 пункты таләпләренә туры килергә тиеш.

5.4.9. Планлы тикшерү белән каралган барлык тикшереп тору чараларын башкару административ гамәлләр башкару нәтиҗәсе була.

### 5.5. «Планнан тыш күчмә тикшерү уздыру» административ процедурасы

5.5.1. Әлеге Административ регламентның 2.4.3 пунктында күрсәтелгән очраклар планнан тыш күчмә тикшерү нигезе була.

5.5.2. Планнан тыш тикшерү предметы эшчәнлекне башкарганда мәҗбүри таләпләрне үтәүдән, Идарә күрсәтмәләрен үтәүдән, кешеләр гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, дәүләт иминлеген тәэмин итүгә зарар китерүне, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне кисәтү чараларын,

шулай ук мондый хокук бозуларны китереп чыгарган затларны җаваплылыкка тарту чараларын уздырудан гыйбарәт.

Планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигез ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәне үтәү срогы тәмамлану булган очракта, мондый тикшерү предметы Идарә биргән күрсәтмәне үтәү генә була.

5.5.3. Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторының планнан тыш күчмә тикшерү башлана торган гамәлләре тәртибе планнан тыш күчмә тикшерү уздыруның әлеге Административ регламентның 5.4.4, 5.4.5 пунктлары белән билгеләнгән гамәлләре тәртибе шикелле үк була .

5.5.4. Планнан тыш күчмә тикшерү уздыру өчен нигез кешеләр гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкярләргә), дәүләт иминлегенә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү, муниципаль норматив актлар белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыклану булса, мондый бозулар кылынган мизгелгә кичекмәстән чаралар күрү зарурлыгына бәйле рәвештә, Идарә егерме дүрт сәгать эчендә, прокуратура органнарына тикшереп тору чаралары уздыру турындагы хәбәре булган кирәкле документларны (планнан тыш күчмә тикшерү уздыруны килештерү турында гариза, шуңа Идарә башлыгының (башлыгы урынбасарының) планнан тыш күчмә тикшерү уздыру турындагы боерыгы һәм аны уздыру өчен нигез хезмәтен үтәгән белешмәләре булган документлар күчермәләре кушып бирелә) җибәреп, кичекмәстән планнан тыш күчмә тикшерү уздырырга керешә.

Бу очракта прокурор яисә аның урынбасары тиешле документлар кергән көнне планнан тыш күчмә тикшерү уздыруны килештерү турында карар кабул итә.

5.5.4. Тикшерү уздыру барышында Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы планнан тыш күчмә тикшерү уздыру турындагы боерыкта күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыра.

5.5.5. Тикшерү уздыру срогы әлеге Административ регламентның 2.3 пункты таләпләренә туры килергә тиеш.

5.5.6. Административ процедураны үтәү нәтиҗәсе планнан тыш күчмә тикшерү белән каралган барлык контроль чараларны үтәү була.

## 5.6. «Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү» административ процедурасы

5.6.1. Административ процедураны башкару өчен нигез тикшерү уздыру тәмамлану була.

5.6.2. Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторлары – Идарә инспекторлары була.

5.6.3. Тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү уздыручы Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы форма буенча ике нөсхәдә акт төзи (типовой

формасы РФ Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган).

Тикшереп тору чаралары нәтиҗәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны яисә РФ КоАП белән каралган һәм әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән административ хокук бозулар билгеләре ачылган очракта, административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү хокукы булган Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы түбәндәге гамәлләрне башкара:

ачылган барлык хокук бозулар очракларын тикшерү актында беркетеп куя;

тикшерү актына уздырылган тикшеренүләр, сынаулар һәм экспертизалар беркетмәләрен яисә бәяләмәләрен, мәҗбүри таләпләрне яисә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозу өчен җаваплы юридик затның, индивидуаль эшкуарның, хезмәткәрләренең аңлатмаларын, ачыкланган бозуларны бетерү турындагы һәм документлар яисә аларның күчермәләрен тикшерү нәтиҗәләренә бәйле бүтән күрсәтмәләрне кушып куя;

әлеге Административ регламентның 5.7 бүлеге нигезендә чаралар күрә.

Үтәлү срогы: тикшерү акты төзү – тикшерү тәмамлануга ук.

Тикшерү актын төзү өчен уздырылган тикшеренүләр, сынаулар, махсус эзләнүләр, экспертизалар нәтиҗәләре буенча бәяләмә алу кирәк булган очракта, тикшерү акты тикшереп тору чарасы тәмамланганнан соң өч эш көненнән дә артмаган срокта төзелә һәм юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә имза салдырып тапшырыла йә, тапшырылуы турындагы хәбәрнамәсе белән, заказлы почта юлламасы рәвешендә җибәрелә, ул Идарә бүлегенең эшләр алып баруында саклanучы акт нөсхәсенә кушып куела.

5.6.4. Тикшерү актында түбәндәгеләр күрсәтелә:

1. тикшерү актын төзү датасы, вакыты һәм урыны;
2. Идарә атамасы;
3. тикшерү уздыру турында Идарә башлыгының (башлыгы урынбасарының) боерыгы номеры;
4. тикшерү уздыручы вазыйфаи зат яисә вазыйфаи затлар фамилиясе, исеме, атасының исеме;
5. тикшерелүче юридик зат атамасы яисә индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме, шулай ук тикшерү барышында шунда булган юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле фамилиясе, исеме, атасының исеме;
6. тикшерү уздыру датасы, вакыты, дәвамлылыгы һәм урыны;
7. тикшерү нәтиҗәләре турында белешмәләр, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозулар турында, аларның характеры турында һәм әлеге бозуларны кылган затлар турында белешмәләр;
8. тикшерү барышында шунда булган юридик затның җитәкчесенең, бүтән вазыйфаи затының яисә вәкаләтле вәкиленең, индивидуаль

эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең тикшерү акты белән танышуы яисә тикшерү акты белән танышудан баш тартуы, аларның имзалары булу яисә имза салудан баш тартуы турында белешмәләр, шулай ук уздырылган тикшерү хакында тикшерүләрне исәпкә алу журналына язмалар кертү йә юридик затта, индивидуаль эшкуарда шундый журнал булмау аркасында мондый язманы кертү мөмкинлеге булмау турында белешмәләр, акт тапшырылуы турында хәбәрнамәсе белән, заказлы почта юлламасы рәвешендә җибәрелә, ул Идарә бүлеге эшендә сакланачы тикшерү акты нөсхәсенә беркетеп куела.

9. тикшерү уздырган вазыйфаи зат яисә вазыйфаи затлар имзалары.

5.6.5. Тикшерү акты төзегәннән соң Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы тикшерү актының бер нөсхәсен юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү актының бер нөсхәсен тикшерү акты белән танышуы йә танышудан баш таруы турында имза салдырып тапшыра. Юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелүче затның тикшерү акты белән танышуы йә танышудан баш тартуы турында имза салудан баш тартуы очрагында, тикшерү акты, тапшырылуы турындагы хәбәрнамәсе белән, заказлы почта юлламасы рәвешендә җибәрелә, ул Идарә бүлеге эшендә сакланучы тикшерү акты нөсхәсенә беркетеп куела.

Үтәлү срогы:

тикшерелүче затны тикшерү акты белән таныштыру һәм тикшерү актын тапшыру – тикшерү тәмамланугa ук;

тикшерү актын заказлы хат итеп җибәрү: тикшереп тору чаралары тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә.

5.6.6. Планнан тыш күчмә тикшерү уздыру өчен аны прокуратура органы белән килештерү таләп ителгән очракта, Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы тикшерү акты күчермәсен тикшерү уздыруны килештерү турында карар кабул иткән прокуратура органына җибәрә.

Үтәлү срогы: тикшерү акты төзелгәннән соң биш эш көне эчендә.

5.6.7. Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы РФ Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган формасы буенча юридик зат, индивидуаль эшкуар алып барырга мөмкин булган тикшерүләрне исәпкә алу журналына язып куя. Язмада Идарәнең атамасы, тикшерү уздыруны башлау һәм тәмамлау даталары, аны уздыру вакыты, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы турында, ачыкланган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турында белешмәләр булырга тиеш, шулай ук анда тикшерү уздыручы вазыйфаи затның яисә вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, атасының исемнәре, аның яисә аларның имзалары күрсәтелә.

Тикшерүләрне исәпкә алу журналы тегеп куелырга, номерлар сугылырга һәм юридик затның, индивидуаль эшкуарның мөһере белән таныкланырга тиеш (мөһере булса).

Тикшерүләрне исәпкә алу журналы булмаганда тикшерү актына тиешле язма ясала.

Үтәлү срогы: тикшерү тәмамлануга ук.

5.6.8. Үзенә карата тикшерү уздырылган юридик зат, индивидуаль эшкуар тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән йә тикшерү актын алганнан соң унбиш көн эчендә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән килешмәгән очракта, тикшерү актына һәм (яисә) ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәгә карата тулаем яисә аның аерым нигезләмәләренә карата язма рәвештә ризасызлыкларын тапшырырга хокуклы. Бу чакта юридик зат, индивидуаль эшкуар бу ризасызлыкларына мондый ризасызылыкларның нигезлелеген раслаучы документларны яисә аларның таныкланган күчермәләрен кушып бирергә йә килешенгән срокта аларны Идарәгә тапшырырга хокуклы.

5.6.9. Административ процедураны үтәү нәтиҗәсе түбәндәгеләр була:

тикшерү акты, үзенең кушымталары белән бергә;

юридик затта, индивидуаль эшкуарда булган тикшерүләрне исәпкә алу журналында уздырылган тикшерү турында язма (юридик затта, индивидуаль эшкуарда тикшерүләрне исәпкә алу журналы булса);

тикшерү уздыруны прокуратура органы белән килештергән очракта – прокуратура органына җибәрелгән тикшерү акты күчермәсе.

### 5.7. «Тикшерү барышында ачыкланган бозулар фактларына карата Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторлары тарафыннан күрелә торган чаралар» административ процедурасы

5.7.1. Идарәнең тикшерү уздыручы баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозулар яисә административ хокук бозулар административ процедураны үтәү өчен нигез була.

5.7.2. Тикшерү барышында ачыкланган бозулар фактларына карата чаралар күрүче, әлеге Административ регламентның 2.5 пункты нигезендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә, административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга хокуклы вазыйфаи затлар – Идарәнең тикшерү уздыручы баш дәүләт инженер-инспекторлары – Идарә инспекторлары.

5.7.3. Мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган очракта, тикшерү нәтиҗәләре буенча Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, ачыкланган хокук бозуларны бетерү срокларын күрсәтеп, аларны бетерү турында һәм (яисә) кешеләр гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларына, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас

объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкярләргә), дәүләт иминлегенә, физик затлар һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә зарар китерүне кисәтү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне кисәтү чараларын, шулай ук федераль законнарда каралган чараларны уздыру турында күрсәтмәләрне рәсмиләштерә һәм бирә.

Күрсәтмә тикшерү актына кушымта була, әлеге Административ регламентка 2 нче кушымтада китерелгән форма нигезендә рәсмиләштерелә һәм юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән бер үк вакытта әлеге Административ регламентның 5.6.5 пункты нигезендә тапшырыла.

Үтәлү срогы: күрсәтмәне рәсмиләштерү һәм тикшерү акты белән бер үк вакытта тапшыру.

5.7.4. Күрсәтмәдә күрсәтелгән бозуларны бетерү срогы тәмамлангач, Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы әлеге Административ регламентның 5.3 и 5.5 пунктларында күрсәтелгән тәртиптә планнан тыш күчмә тикшерүне әзерли һәм уздыра. Күрсәтмәне үтәүне планнан тыш күчмә тикшерү нәтиҗәләре әлеге Административ регламентның 5.6 пункты нигезендә рәсмиләштерелә.

Тикшерелүче зат күрсәтмәне билгеләнгән срокларда үтәмәгән очракта, Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы административ хокук бозулар турында РФ КоАПның 19.5 статьясындагы 1 өлешендә каралган административ хокук бозулар турында беркетмәне КоАП РФның 28.2 статьясы таләпләре нигезендә һәм әлеге Административ регламентка 3 нче кушымтада китерелгән форма нигезендә төзи һәм РФ КоАПта каралган тәртиптә административ хокук бозулар турында беркетмәне карауны тәэмин итә.

Үтәлү срогы: беркетмә төзү – административ хокук бозу ачыклаганнан соң кичекмәстән.

Вакыйгаларны йә үзләренә карата административ хокук бозу турында эш кузгатыла торган физик затлар турында күрсәткечләрне яисә һәм юридик затлар турында белешмәләрне өстәмә өйрәнү таләп ителгән очракта, административ хокук бозу турындагы беркетмә административ хокук бозу ачыкланган мизгелдән ике тәүлек дәвамында төзелә.

5.7.5. Әгәр тикшерү әлеге Административ регламентның 2.4.3 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча алып барылса, административ хокук бозу ачыкланган очракта, Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы РФ КоАПның 9.3 статьясында каралган административ хокук бозу турында беркетмәне РФ КоАПның 28.2 статьясы таләпләре нигезендә һәм әлеге Административ регламентка 3 нче кушымтада китерелгән форма нигезендә төзи һәм аны карауны билгеләнгән тәртиптә тәэмин итә. Административ хокук бозу кылган өчен шул ук хокук бозучы һәм башка затлар тарафыннан яңа хокук бозуларны кисәтү максатларында,

Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы РФ КоАПта каралган административ җәзаны билгели һәм куллана.

Үтәлү срогы: әлеге Административ регламентның 5.7.4 пунктчасындагы өченче һәм дүртенче абзацлар нигезендә.

5.7.6. КоАПның 8.22, 8.23 статьяларында (Идарә күзәтчелегендәге техника өлешендә), 9.3 статьясында, 12.37 статьсында (Идарә күзәтчелегендәге техника өлешендә), 19.22 статьясының һәм өлешендә каралган административ хокук бозулар фактлары билгеләнгәндә машиналар һәм җайланмаларның техник торышы өлкәсе хокук бозулар ачыкланган очракта, РФ КоАПның 28.2 статьясы таләпләре нигезендә һәм әлеге Административ регламентка 3 нче кушымтада китерелгән форма нигезендә административ хокук бозулар турында беркетмә төзелә һәм аны карауны билгеләнгән тәртиптә тәэмин ителә.

Үтәлү срогы: әлеге Административ регламентның 5.7.4 пунктчасындагы өченче һәм дүртенче абзацлар нигезендә.

5.7.7. Тикшерү уздырганда юридик затның, аның филиалының, вәкиллегенең, структур бүлекчәсенең, индивидуаль эшкуарның эшчәнлеге, алар эксплуатацияли торган биналарның, корылмаларның, төзелмәләрнең, урыннарның, шуңа охшаш объектларның, транспорт чарааларының, алар җитештерә һәм реализацияли торган товарларның (башкарган эшләрнең, күрсәткән хезмәтләрнең) гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкярләргә), дәүләт иминлегенә турыдан-туры куркыныч тудырган, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр тудырган (гадәттән тыш хәлләр янаган) очракта, Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы зарар китерүне булдырмас өчен яисә зарар китерүне туктату өчен юридик затның, аның филиалының, вәкиллегенең, структур бүлекчәсенең, индивидуаль эшкуарның эшчәнлеген вакытлыча тыеп тору, гражданнар гомеренә һәм сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә зарар китерүче продукцияләрен әйләнештән алу рәвешендә РФ КоАПта билгеләнгән тәртиптә кичекмәстән чаралар күрергә һәм гражданнарга, шулай ук юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга зарар китерү куркынычы булу һәм аларны бетерү алымнары турында мөмкин булган теләсә нинди ысул белән мәгълүмат җиткерергә тиеш.

5.7.8. Административ хокук бозу турында эш кузгату өчен нигезләрне билгеләү максатларында кирәк булган очракта, Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы административ хокук бозу турында эшләр алып баруның түбәндәге чараларын куллана:

юридик затныкы яисә индивидуаль эшкуарныкы булган биналарны, территорияләрне һәм шунда булган әйберләрне һәм документларны карау турында РФ КоАПның 27.8 статьясы нигезендә беркетмә төзелә;

әйберләрне һәм документларны алу турында беркетмә төзелә йә РФ КоАПның 27.10 статьясы нигезендә административ хокук бозу турындагы беркетмәгә язма ясала.

Үтәлү срогы: әлеге Административ регламентның 5.7.4 пунктчасындагы өченче һәм дүртенче абзацлар нигезендә.

5.7.9. Дәүләт күзәтчелеген башкару барышында әлеге тикшерү объекты булмаган законнар таләпләрен бозулар ачыкланса, Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы Россия Федерациясенең тиешле дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына мондый хокук бозулар турында мәгълүмат (белешмәләр) җибәрә.

5.7.10. Идарәнең административ хокук бозу турындагы эшне караучы баш дәүләт инженер-инспекторы административ хокук бозу сәбәпләрен һәм аны кылуга китергән шартларны билгеләгәндә, шушы сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чаралар күрү турында тиешле оешмаларга һәм вазыйфаи затларга күрсәтмә кертә.

Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы үз вәкаләтләре нигезендә административ хокук бозу турында беркетмә төзүне һәм материалларны административ хокук бозу турындагы эшне карау өчен судка җибәрүне тәэмин иткән очракта, ул юридик зат, аны гамәлгә куючы адресына, аның исеменнән ышанычнамәсез генә эш йөртү хокукы булган зат адресына материаллар белән бергә шушы сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чаралар күрү турында күрсәтмә җибәрә.

Үтәлү срогы: административ хокук бозу турында беркетмә рәсмиләштерелгәннән соң өч эш көне эчендә.

Оешма, вазыйфаи зат административ хокук бозуга китергән сәбәпләр һәм шартларны бетерү хакындагы күрсәтмәне аны алган көннән соң бер ай эчендә карарга һәм күрелгән чаралар турында Идарәгә хәбәр итәргә тиеш. Күрсәтмәдә административ хокук бозуга китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү хакында күрсәтелгән мәҗбүри күрсәтмәләрне үтәмәгән очракта, шушы затлар РФ КоАПның 19.6 статьясы буенча административ җаваплылыкка тартылырга мөмкин.

5.7.11. «Тикшерү барышында ачыкланган бозулар фактларына карата Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторлары тарафыннан күрелә торган чаралар» административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе түбәндәгеләр була:

тикшерү актына кушымта булган күрсәтмә;

РФ КоАПта каралган административ хокук бозу очрагы:

административ хокук бозу турында беркетмә;

административ хокук бозуга китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү хакында күрсәтмә (кирәк булса).

5.7.12. Тикшерү тәмамланганнан соң Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы тикшерү нәтиҗәләре буенча тиешле мәгълүматны, тикшерү нәтиҗәсен беркетү максатында, Идарәнең рәсми сайтында урнаштыруны оештыра.

## 6. ДӘҮЛӘТ ВАЗЫЙФАСЫН БАШКАРУНЫ ТИКШЕРЕП ТОРУ ТӘРТИБЕ ҺӘМ РӘВЕШЛӘРЕ

6.1. Дәүләт вазыйфасын башкаруны тикшереп тору Идарә башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.2. Идарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Административ регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт вазыйфасын башкаруга карата таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актларны үтәүне һәм башкаруны, шулай ук алар кабул иткән карарларны агымдагы тикшереп тору, Идарәнең башлыгы урынбасары, Идарә бүлекләре башлыклары, Идарәнең күзәтчелек һәм автоматлаштырып исәпкә алу бүлеге башлыгы һәм Идарәнең вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.3. Идарәнең дәүләт вазыйфасын башкаруны агымдагы тикшереп торуга вәкаләтле хезмәткәрләре исемлеге, мондый тикшереп торуны башкару тәртибе һәм даимилеге Идарә акты белән билгеләнә.

6.4. Идарәнең күзәтчелек һәм автоматлаштырып исәпкә алу бүлеге башлыгы һәм Идарәнең вәкаләтле вазыйфаи затлары дәүләт вазыйфасын башкарганда дәүләт вазыйфасын башкаруның тулылыгын һәм сыйфатын, законнар һәм әлеге Административ регламентны үтәүне агымдагы тикшереп торуны гамәлгә ашыра, Идарәнең вазыйфаи затларының хезмәт бурычларын үтәмәүләре (тиешенчә үтәмәүләре) очракларында, Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый вазыйфаи затларга карата хезмәт тикшерүләре оештыру һәм чаралар күрү өчен Идарә башлыгына мәгълүмат тапшыра.

6.5. Идарә тарафыннан дәүләт вазыйфасын башкаруның тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп торуга дәүләт вазыйфасын башкаруда турыдан-туры катнашучы Идарә бүлеге тарафыннан планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыру, кызыксынучы затларның Идарәнең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләре булган мөрәҗәгатьләрен карау һәм аларга җавапларны әзерләү, дәүләт вазыйфасын башкарганда тикшерелүче затларның хокукларын бозуларны ачыклау һәм бетерү керә.

Тикшерүләр Идарә башлыгыны (башлыгы урынбасарының) боерыгы нигезендә уздырыла. Тикшерүләр нәтиҗәләре акт рәвешендә рәсмиләштерелә, анда дәүләт вазыйфасын башкарганда Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозулар булмау йә булу һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр беркетеп куела.

Әлеге Административ регламентның үтәлешен гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар тарафыннан үтәүне тикшереп тору Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә берләшмәләр һәм оешмалар уставлары буенча гамәлгә ашырыла. Дәүләт вазыйфасын башкаруны иҗтимагый тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган нәтиҗәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә һичшиксез каралырга тиеш.

6.6. Идарә эшенең еллык планы нигезендә юридик затның һәм индивидуаль эшкуарның дәүләт вазыйфасын башкаруның тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору буенча планлы тикшерүләр уздырыла.

Планлы тикшерүләргә түбәндәгеләр керә:

1) дәүләт вазыйфасын башкару барышында документларны рәсмиләштерү дөреслеге;

2) дәүләт вазыйфасын башкару процедурасының Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары таләпләренә һәм әлеге Административ регламентка туры килүе.

6.7. Дәүләт вазыйфасын башкаруның тулылыгын һәм сыйфатын планнан тыш тикшерүләр Идарәнең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата яисә дәүләт вазыйфасын башкару барышында кабул ителгән карарларына карата гражданнарның шикаятьләре (дәгъвалары) нигезендә уздырыла.

6.8. Дәүләт вазыйфасын башкару өчен җаваплы Идарәнең вазыйфаи затлары дәүләт вазыйфасын башкару барышында гамәлләре (гамәл кылмавы) һәм кабул ителгән карарлары өчен җаваплы була.

6.9. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәләре буенча дәүләт вазыйфасын башкарганда Идарәнең вазыйфаи затының ачыкланган хокук бозуларын һәм аларны бетерү срокларын күрсәтеп, акт төзелә һәм чаралар күрелә, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

Идарәнең вазыйфаи затлары җаваплылыгы Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә хезмәт регламентларында беркетелә.

## 7. ДӘҮЛӘТ ВАЗЫЙФАСЫН БАШКАРУЧЫ ОРГАННЫҢ, ШУЛАЙ УК АНЫҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ КАРАРЛАРЫНА ҺӘМ ГАМӘЛЛӘРЕНӘ (ГАМӘЛ КЫЛМАВЫНА) КАРАТА СУДКА КАДӘР (СУДТАН ТЫШ) ШИКАЯТЬ БЕЛДЕРҮ

7.1. Кызыксынучы затлар (алга таба – гариза бирүчеләр) дәүләт вазыйфасын башкарганда катнашучы вазыйфаи затларның башкарылган (кабул ителгән) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белән Идарә башлыгы исеменә йә югарырак органга (югарырак вазыйфаи затка) мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

7.2. Гариза бирүчеләр мөрәҗәгать белән шәхсән мөрәҗәгать итәргә яисә язма рәвештә почта аша яисә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, шул исәптән Идарәнең рәсми сайтын, Порталны кулланып, электрон документ рәвешендә җибәрергә хокуклы.

Идарәнең вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү предметы Идарәнең вазыйфаи затларының дәүләт вазыйфасын башкарганда кабул ителгән һәм башкарылган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) була.

7.4. Идарәгә яисә югарырак вазыйфаи затка кергән шикаять аларның компетенциясе нигезендә һичшиксез каралырга тиеш. Судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне караудан баш тарту яисә карауны туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

7.5. Түбәндәге очракларда шикаятькә җавап бирелми йә анда куелган сорауларның асылы буенча җавап бирелми:

шикаятьтә юридик затның атамасы күрсәтелмәгән (гариза бирүче юридик зат булса), шикаятьне җибәрүче гариза бирүченең фамилиясе яисә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән;

шикаятьтә оятсыз йә мәсхәрәләүче гыйбарәләр булу, вазыйфаи зат, аның гаилә әгъзалары гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булу (вазыйфаи зат шикаятьне анда куелган мәсьәләләр асылы буенча җавапсыз калдырырга һәм шикаятьне җибәргән гариза бирүчегә хокукыннан явыз ниятләрдә фадалануның рөхсәт ителмәве турында хәбәр итәргә хокуклы);

шикаять тексты укылмаслык булу (мондый очракта шикаять шулай ук дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенциясе нигезендә карау өчен җибәрелмәскә тиеш, бу хакта шикаятьне теркәгән көннән җиде көн эчендә гариза бирүчегә җибәрелә, әгәр аның фамилиясе (юридик затның атамасы) һәм почта адресы укырлык булса;

әгәр шикаятьтә элек җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә асылы буенча гариза бирүчегә берничә мәртәбә шушы ук сорау буенча язма җаваплар җибәрелгән булса, һәм бу чакта шикаятьтә яңа дәлилләр яисә хәлләр китерелмәсә (әлеге шикаять һәм элегрәк җибәрелгән шикаятьләр бер үк дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә бер үк вазыйфаи затка җибәрелгән булса. Гариза бирүчегә язышуны туктату турындагы бу карар хакында хәбәр ителә);

шикаятьтә куелган сорауның асылы буенча җавап бирү дәүләт яисә федераль закон белән саклана торган бүтән серне чишмичә мөмкин булмаса, (җибәргән гариза бирүчегә анда куелган сорауга асылы буенча җавап бирү әлеге белешмәләрне чишү рөхсәт ителмәүгә бәйле рәвештә мөмкин булмау хәбәр ителә).

Шикаять аның компетенциясе нигезендә дәүләт органына җибәрелергә тиеш, әгәр шушы шикаятьтә әзерләнә торган, кылына торган яисә кылынган хокукка каршы гамәл турында, шулай ук хокукка каршы гамәл әзерләүче, кылучы яисә кылган зат турында белешмәләр булса.

Суд карарына карата белдерелгән шикаять, шушы суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып, теркәлгәннән соң җиде көн эчендә гариза бирүчегә кире кайтарыла.

Шикаятьтә куелган сорауларга асылы буенча җавап бирелмәү сәбәпләре киләчәктә бетерелгән очракта, гариза бирүче шикаятьне яңадан Идарәгә яисә аның вазыйфаи затына җибәрергә хокуклы.

7.6. Шикаятьтә гариза бирүче һичшиксез үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булса), электрон почтасы адресын, әгәр җавап электрон документ рәвешендә җибәрелергә тиеш булса, һәм почта адресын, әгәр җавап язма рәвештә җибәрелергә тиеш булса, Идарә атамасын, йә язма

мөрәҗәгать җибәрелә торган вазыйфаи зат фамилиясен, исемен, атасының исемен, йә тиешле затның вазыйфасын күрсәтергә тиеш.

Гариза бирүче шикаятькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон рәвештә кушып бирергә йә күрсәтелгән документларны һәм материалларны, аларның күчермәләрен язма рәвештә җибәрергә хокуклы.

Шикаятьне караганда гариза бирүче өстәмә документлар һәм материаллар тапшырырга йә, аларны таләп итеп алуны сорап, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

7.7. Идарәгә шәхсән гариза бирүченең үзеннән (гариза бирүченең вәкаләтле вәкиленнән) шикаять керү яисә почта юлламасы рәвешендә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, шул исәптән Идарәнең рәсми сайтын, Порталны кулланып, электрон документ рәвешендә судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процедурасын башлау өчен нигез була.

7.8. Кызыксынучы затлар шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны алуга хокуклы була. Мондый мәгълүматны һәм документларны алу өчен кызыксынучы затлар Идарә адресына язма рәвештә тиешле гарызнамә җибәрергә тиеш. Идарәнең гарызнамәне үтәү йөкләмәсе бирелгән вазыйфаи затлары соратыла торган белешмәләрне һәм документларны гарызнамәне теркәгән көннән 30 календарь көн эчендә бирәләр.

7.9. Идарәнең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять Идарә башлыгына җибәрелергә мөмкин. Идарә башлыгы гамәлләренә (гамәл кылмавына), карарларына карата шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелергә мөмкин.

7.10. Хәл ителүе Идарә яисә аның вазыйфаи затлары компетенциясенә кертелмәгән сораулары булган шикаятьтә куелган сорауларны хәл итү үз компетенциясенә кертелгән тиешле органга яисә тиешле вазыйфаи затка шикаять теркәлгәннән соң җиде көн эчендә җибәрелә, гариза бирүчегә шикаятьне башка адреска җибәрү турында хәбәр ителә.

7.11. Идарәгә яисә вазыйфаи затка кергән шикаять аларның компетенциясе нигезендә аны теркәгәннән соң 30 календарь көн эчендә карала.

Аерым очракларда, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән каралган очракларда, Идарә башлыгы йә шуңа вәкаләтле вазыйфаи заты шикаятьне карау срогын 30 календарь көннән дә арттырырга хокуклы түгел, ул шикаять җибәргән гариза бирүчегә аны карау срогын озайту турында хәбәр итә.

7.12. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү нәтиҗәләре түбәндәгеләр була:

1) дәүләт вазыйфасын башкарганда кабул ителгән (башкарылган) гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм карарларга карата судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндерү, шулардан:

хезмәт тикшерүе барышында вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) дәүләт вазыйфасын тиешенчә үтәмәүләре фактлары ачылган очракта, Россия

Федерациясе законнары нигезендә вазыйфаи затка (вазыйфаи затларга) карата чаралар күрү;

хокуклары һәм (яисә) законлы мәнфәгатьләре бозылган гариза бирүчегә Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата кабул ителгән чаралар турында мондый чаралар кабул ителгәннән соң ун көн эчендә язма рәвештә хәбәр итү;

2) дәүләт вазыйфасын башкарганда кабул ителгән (башкарылган) гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм карарларга карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирүне канәгатьләндерми калдыру, мондый карарны нигезләп язма рәвештә хәбәр итү юлы белән.

Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча язма җавапка Идарә башлыгы йә Идарә башлыгы урынбасары вәкаләт тапшырган вәкаләтле вәкил имза сала һәм аны гариза бирүчегә җибәрә.

Электрон документ рәвешендә кергән шикаятькә җавап шикаятьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча яисә язма рәвештә шикаятьтә күрсәтелгән почта адресы буенча җибәрелә.

Административ регламентка
1 нче кушымта

## Күзәтчелек объектлары булган машиналар һәм җайланмалар исемлеге

1. Авыл хуҗалыгы машиналары:

авыл хуҗалыгы культураларын игү һәм урып-җыюдан соң эшкәртү өчен машиналар:

туфрак эшкәртү, ашламалар кертү һәм үсемлекләр корткычларына һәм авыруларына каршы көрәш буенча гомуми билгеләнештәге машиналар;

бөртекләрне, бөртекле-кузаклыларны, май культураларын һәм үләннәрнең орлык өлешләрен игү, җыю һәм урып-җыюдан соң эшкәртү өчен машиналар; үләннәрне һәм силос культураларын җыю өчен машиналар; техник культураларны игү һәм урып-җыю өчен машиналар; яшелчә культураларын һәм бәрәңге игү өчен машиналар; якланган грунтта эшләү өчен машиналар;

күпьеллык үсентеләрне утырту һәм игү, аларны эшкәртү продукциясен урып-җыю һәм урып-җыюдан соң эшкәртү өчен машиналар;

мелиорация һәм урман хуҗалыгы өчен машиналар; башка машиналар.

2. Терлекчелек өчен машиналар һәм җайланмалар – авыл хуҗалыгы терлекләрен һәм кошларны асрау, терлекчелек продукциясен алу һәм беренчел эшкәртү өчен машиналар һәм җайланмалар:

су белән тәэмин итү һәм эчертү машиналары һәм җайланмалары;

терлек азыгын транспортлау һәм өләшү машиналары һәм җайланмалары;

сыер саву машиналары, сөтне беренчел эшкәртү машиналары һәм җайланмалары;

тирес җыю һәм аны беренчел эшкәртү өчен машиналар һәм җайланмалар;

микроклимат булдыру өчен җайланмалар;

терлек йонын алу пунктлары җайланмалары;

кош фабрикалары машиналары һәм җайланмалары;

терлек асрау өчен аран-терлек тоту җайланмалары; терлекләрне асрау буенча ветеринар-санитар җайланмалар; терлек азыгы әзерләү җайланмалары; башка машиналар һәм җайланмалар.

3. Эшкәртү предприятиеләре машиналары һәм җайланмалары – авыл хуҗалыгы продукциясен теге яисә бу азык-төлек төре, фураж һәм халык куллану товарлары итеп эшкәртүче машиналар һәм җайланмалар:

сөт цехлары һәм заводлары машиналары һәм җайланмалары; ит эшкәртү линияләре һәм ит комбинатларының машиналар комплекслары;

он тарттыру предприятиеләренең, икмәк-күмәч әйберләре җитештерү цехларының һәм заводларының, катнаш терлек азыгы җитештерү цехларының һәм предприятиеләренең машиналары һәм җайланмалары;

яшелчә, җиләк-җимеш эшкәртүче консерв заводлары; эшкәртү тармаклары предприятиеләренең башка машиналары һәм җайланмалары.

4. Ремонт остаханәләренең машиналары һәм җайланмалары:

юу машиналары һәм җайланмалары; күтәрү-транспорт машиналары һәм җайланмалары; шиннар монтажлау җайланмалары;

эретеп ябыштыру машиналары һәм җайланмалары; станок җайланмалары; тимерчелек җайланмалары;

техник хезмәт күрсәтү машиналары һәм җайланмалары; вентиляция җайланмалары; башка машиналар һәм җайланмалар.

5. Нефть складлары һәм ягулык салу машиналары һәм җайланмалары: резервуарлар, цистерналар һәм торбаүткәргечләр; ягулык өләшү колонкалары һәм машиналары;

насос станцияләре һәм стояклары.

Административ регламентка
2 нче кушымта
Форма

**ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘСЕНДӘ АЧЫКЛАНГАН БОЗУЛАРНЫ БЕТЕРҮ ТУРЫНДА ДӘҮЛӘТ ТЕХНИК КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИДАРӘСЕНЕҢ ДӘҮЛӘТ ИНЖЕНЕР-ИНСПЕКТОРЫ КҮРСӘТМӘСЕ №_____**

______________________________________________________________________
______________________________ **(юридик зат өчен күрсәтергә: атамасы һәм адресы; вазыйфаи зат өчен: ф.ис.ат. ис., вазыйфасы, оешманың атамасы һәм адресы; физик зат өчен: ф.ис.ат. ис. һәм адресы)**

Россия Федерациясендә машианаларның һәм башка төрдәге техниканың техник торышына дәүләт күзәтчелеге турында Россия Федерациясе Министрлар Советы-Хөкүмәтенең 1993 елның 13 декабрендәге №1291 карары белән расланган нигезләмәгә таянып, Сезгә мин ачыклаган бозуларны бетерү чараларын күрергә йөклим

| № т/с | Ачыкланган бозулар, алар белән билгеләнгән бозылган нормалар һәм документлар | Үтәлү срогы |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

_______________*муниципаль район буенча Дәүләт техник күзәтчелегенең баш дәүләт инженер-инспекторы* «___» ____________ 20___ елның

_________________________ _____________________
М.У.

(фамилиясе ис. ат. ис.)

*Күрсәтмә алынды* «___» _______________ 20______ елның

_____________________

(имзасы)

______________________________________________________________________
________________

(вазыйфасы, ф.ис.ат. ис.)

Күрсәтмәне үтәү турында тамга

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
____________

____________________ ____________________ ____________________ *М.У.*

(вазыйфасы) (имзасы) (фамилиясе ис. ат.ис.)

20___ елның «_____» _________

Административ регламентка
3 нче кушымта
Форма

# АДМИНИСТРАТИВ ХОКУК БОЗУ ТУРЫНДА БЕРКЕТМӘ

20___елның «____»_______________ ____сәг. __________ мин._____________________________
(төзү датасы) (төзү урыны)

Мин,______________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________
(беркетмә төзегән вазыйфаи затның вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары)

**Әлеге беркетмәне түбәндәгеләр турында төзедем**

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

(административ җаваплылыкка тартылган зат фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Туу датасы һәм урыны

___________________________________________________________________________

________________

Яшәү урынының адресы

_________________________________________________________________тел.__________

________________

Эшләүче

_______________________________________________________________________тел.____

______________________
(оешма атамасы һәм адресы, вазыйфасы)

Тракторист-машинист таныклыгы. Сериясе __________________№
______________________ Категориясе________________________

Машина, җайланма турында белешмәләр ________________________________________

___________________________________________________________________________
(атамасы, маркасы, дәүләт теркәү тамгасы (булса)

Кемнеке булуы

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, оешма, адресы)

Дәүләт техник күзәтчелеге идарәсенең дәүләт инспекциясендә исәптә тора

______________________________________________________________

«____»_____________20_____елның ________сәг. ______мин.

______________________________________________________________

Җаваплылыгы Россия Федерациясе Административ кодексының _____статьясы _________ өлеше белән каралган хокук бозу кылган, түбәндәгечә белдерелә

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
________________________

Таныклаучылар.

1. Фамилиясе______________________ Исеме ______________________

Атасының исеме______________________

Яшәү урыны адресы

______________________________________________________________________
____________

2. Фамилиясе______________________ Исеме ______________________

Атасының исеме______________________

Яшәү урыны адресы

______________________________________________________________________
____________

РФ КоАПның 25.6 статьясы белән каралган хокуклар һәм бурычлар аңлатылды

______________________________________________________________________

(таныклаучылар имзалары)

Үзләренә карата административ хокук бозулар турында эш кузгатылган затлар аңлатмалары:

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
________________

(имзасы)

Эшне хәл итү өчен кирәкле бүтән белешмәләр

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
________________________________

Беркетмәгә кушып бирелә:

______________________________________________________________________
____________
______________________________________________________________________
________________________________

Административ хокук бозуны карау урыны һәм вакыты

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

миңа аңлатылды______________________________

(адресы, датасы, урыны)

(имзасы)

Беркетмә белән таныштым. РФ КоАПның 25.1 статьясы белән каралган хокуклар һәм бурычлар, миңа аңлатылды______________________

(имзасы)

Беркетмә күчермәсен алдым. Административ җаваплылыкка тартылган зат имзасы

________________________

Беркетмә төзегән зат имзасы ______________________

Административ регламентка
4 нче кушымта

## Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторлары белән бәйләнешкә керү күрсәткечләре

| Район, шәһәр | Телефон коды | Телефоны | Почта индексы | Адресы |
|---|---|---|---|---|
| Әгерҗе | 85551 | 2-20-43 | 422230 | Әгерҗе шәһәре, Гагарин ур., 70 |
| Азнакай | 85592 | 7-02-76 | 423330 | Азнакай шәһәре, Нефтьчеләр ур., 23 а |
| Аксубай | 84344 | 2-89-18 | 423060 | Аксубай штп, Совет ур., 7а |
| Актаныш | 85552 | 3-13-16 | 423740 | Актаныш авылы, Ленин ур., 7 |
| Алексеевск | 84341 | 2-62-74 | 422900 | Алексеевск штп, Чистай ур., 6 |
| Әлки | 84346 | 2-16-68 | 422870 | Базарлы Матак авылы, Солнечная ур.,1 |
| Әлмәт | 88553 | 37-47-87 | 423450 | Әлмәт шәһәре, Агрохимсервис бинасы |
| Апас | 84376 | 21-4-54 | 422350 | Апас авылы, ул. Гагарин ур., 11 |
| Арча | 84366 | 3-22-66 | 422000 | Прча штп, Совет мәйданы ур., 12 |
| Әтнә | 84369 | 2-10-43 | 422750 | Олы Әтнә авылы, Совет ур., 38 |
| Баулы | 85569 | 5-86-25 | 423930 | Баулы шәһәре, Вәһапов ур., 46а |
| Балтач | 84368 | 2-52-33 | 422250 | Балтач штп, Космонавтлар ур., 1 |
| Бөгелмә | 85594 | 4-14-46 | 423230 | Бөгелмә шәһәре, Я. Гашек ур., 3/2 |
| Буа | 84374 | 3-15-97 | 422400 | Буа шәһәре, Космовский ур., 31 |
| Югары Ослан | 84379 | 2-14-26 | 422570 | Югары Ослан авылы, Чехов ур., 18 |
| Биектау | 84365 | 2-31-46 | 422700 | Биек Тау п., Мәктәп ур., 17 |
| Чүпрәле | 84375 | 2-23-79 | 422470 | Иске Чүпрәле авылы, Дзержинский ур., 6 |
| Алабуга | 85557 | 78-6-78 | 423604 | Алабуга шәһәре, Беренче Май ур., 50 |
| Зәй | 85558 | 7-08-15 | 423520 | Зәй шәһәре, Н.Крупская ур., 6 |
| Зеленодольск | 84371 | 5-77-88 | 422540 | Зеленодольск шәһәре, Ленин ур., 38 |
| Кайбыч | 84370 | 2-11-15 | 422330 | Олы Кайбыч штп, Гисмәтуллин ур., 3 |
| Кама-Тамагы | 84377 | 2-19-09 | 422820 | Кама Тамагы штп, К.Маркс ур., 2 |
| Кукмара | 84364 | 2-74-86 | 422110 | Кукмара штп, Ленин ур., 28 |
| Лаеш | 84378 | 2-81-80 | 422610 | Лаеш штп, Маяковский ур., 19а |
| Лениногорск | 85595 | 5-02-44 | 423250 | Лениногорск шәһәре, Гончаров ур., 1 |
| Мамадыш | 85563 | 3-34-16 | 422192 | Мамадыш шәһәре, Совет ур., 2б |
| Менделеевск | 85549 | 2-16-68 | 423650 | Менделеевск шәһәре, Фомин ур., 19 |
| Минзәлә | 85555 | 3-27-92 | 423700 | Минзәлә шәһәре, Ленина ур., 80 |
| Мөслим | 85556 | 2-59-96 | 423970 | Мөслим авылы, Пушкин ур., 43 а |
| Түбән Кама | 8555 | 47-32-28 | 423550 | Түбән Кама шәһәре, Корабль ур., 40 |
| Яңа Чишмә | 84348 | 2-21-37 | 423190 | Яңа Чишмә авылы, Совет ур., 68 |
| Нурлат | 84345 | 2-06-93 | 423040 | Нурлат шәһәре, Совет ур., 117 |
| Питрәч | 84367 | 3-06-59 | 422770 | Питрәч авылы, Совет ур., 20 |
| Балык Бистәсе | 84361 | 2-34-97 | 422650 | Балык Бистәсе авылы, Ленин ур., 48 |
| Саба | 84362 | 2-32-66 | 422060 | Байлар Сабасы авылы, Г. Закиров ур., 52 |
| Сарман | 85559 | 2-50-57 | 423362 | Сарман авылы, Куйбышев ур., 36 |
| Спас | 84347 | 3-03-83 | 422840 | Болгар шәһәре, Широнов ур., 17 |
| Тәтеш | 84373 | 2-55-60 | 422370 | Тәтеш шәһәре, Свердлов ур., 61 |
| Тукай | 8552 | 70-02-44 | 423800 | Чаллы шәһәре, М. Җәлил пр., 46 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Теләче | 84360 | 2-13-19 | 422080 | Теләче авылы, Ленин ур., 40 |
| Чирмешән | 84396 | 2-24-36 | 423100 | Чирмешән авылы, Техническая ур., 36 |
| Чистай | 84342 | 5-25-60 | 422980 | Чистай шәһәре, К.Маркс ур., 61 |
| Ютазы | 85593 | 2-73-13 | 423950 | Урыссу штп, Пушкин ур., 38 |
| Казан шәһәре | 843 | 273-54-50 | 420073 | Казань шәһәре, Спорт ур., 33 |

Административ регламентка
5 нче кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе
аппаратында шәхсән кабул итү графигы

| **Фамилиясе, исеме, атасының исеме** | **Биләгән вазыйфасы** | **Кабул итү көннәре һәм сәгатьләре** |
|---|---|---|
| Зыятдинов Радик Рәгыйп улы | Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе башлыгы | дүшәмбе 15.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр |
| Халиков Мөнир Әфрәем улы | Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе башлыгы урынбасары | сишәмбе 15.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр |

Административ регламентка
6 нчы кушымта

# Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе баш инженер-инспекторларының шәхсән кабул итү графигы

| № т/с | Татарстан Республикасы районнары һәм шәһәрләре | Кабул итү көннәре һәм сәгатьләре |
|---|---|---|
| 1 | Әгерже | дүшәмбе, пәнҗешәмбе 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр |
| 2 | Азнакай | дүшәмбе, сишәмбе, җомга 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр |
| 3 | Аксубай | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 12.00 җомга 8.00 сәгатьтән алып 15.45 сәгатькә кадәр |
| 4 | Актаныш | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 17.00; җомга 8.00 сәгатьтән алып 15.45 сәгатькә кадәр |
| 5 | Алексеевск | сишәмбе, җомга 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр |
| 6 | Әлки | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 17.00; җомга 8.00 сәгатьтән алып 15.45 сәгатькә кадәр |
| 7 | Әлмәт | дүшәмбе- сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр; чәршәмбе 8.00 сәгатьтән алып 12.00, җомга 8.00 сәгатьтән алып 15.45 сәгатькә кадәр |
| 8 | Апас | сишәмбе, җомга 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр |
| 9 | Арча | сишәмбе, җомга 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр |
| 10 | Әтнә | сишәмбе, җомга 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр |
| 11 | Баулы | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 11.00 сәгатькә кадәр; җомга 13.00 сәгатьтән алып 15.00 сәгатькә кадәр |
| 12 | Балтач | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр, җомга 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр |
| 13 | Бөгелмә | дүшәмбе, чәршәмбе, җомга 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр |
| 14 | Буа | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр; җомга 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр |
| 15 | Югары Ослан | сишәмбе 8.30 сәгатьтән алып 16.00 сәгатькә кадәр; пәнҗешәмбе 8.30 сәгатьтән алып 16.00 сәгатькә кадәр |
| 16 | Биектау | сишәмбе 13.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр; пәнҗешәмбе 13.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр |
| 17 | Чүпрәле | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр; җомга 8.00 сәгатьтән алып 15.00 сәгатькә кадәр |
| 18 | Алабуга | дүшәмбе 13.00 сәгатьтән алып 16.00 сәгатькә кадәр; сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 16.00 сәгатькә кадәр; җомга 8.00 сәгатьтән алып 15.45 сәгатькә кадәр |
| 19 | Зәй | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр; җомга 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр |

| | | |
|---|---|---|
| 20 | Зеленодольск | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр; җомга 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр |
| 21 | Кайбыч | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр; җомга 8.00 сәгатьтән алып 15.45 сәгатькә кадәр |
| 22 | Кама Тамагы | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр; җомга 8.00 сәгатьтән алып 15.45 сәгатькә кадәр |
| 23 | Кукмара | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр; җомга 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр |
| 24 | Лаеш | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр; җомга 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр |
| 25 | Лениногорск | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 15.00 сәгатькә кадәр; пәнҗешәмбе 8.00 сәгатьтән алып 15.00 сәгатькә кадәр |
| 26 | Мамадыш | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр; җомга 8.00 сәгатьтән алып 15.45 сәгатькә кадәр |
| 27 | Менделеевск | сишәмбе, җомга 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр |
| 28 | Минзәлә | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр; җомга 8.00 сәгатьтән алып 15.45 сәгатькә кадәр |
| 29 | Мөслим | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 16.00 сәгатькә кадәр; җомга 8.00 сәгатьтән алып 15.45 сәгатькә кадәр |
| 30 | Түбән Кама | дүшәмбе, сишәмбе, пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән алып 15.00 сәгатькә кадәр |
| 31 | Яңа Чишмә | сишәмбе, җомга 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр |
| 32 | Нурлат | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр; җомга 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр |
| 33 | Питрәч | дүшәмбе 9.00 сәгатьтән алып 11.00 сәгатькә кадәр; пәнҗешәмбе с 9.00 сәгатьтән алып 11.00 сәгатькә кадәр |
| 34 | Балык Бистәсе | сишәмбе, җомга 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр |
| 35 | Саба | сишәмбе 8-00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр; җомга 8-00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр |
| 36 | Сарман | сишәмбе, пәнҗешәмбе 8.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр |
| 37 | Спас | сишәмбе, пәнҗешәмбе 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр |
| 38 | Тәтеш | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр; җомга 8.00 сәгатьтән алып 15.30 сәгатькә кадәр |
| 39 | Тукай | дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе 8.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр |
| 40 | Теләче | сишәмбе, җомга 8.00-12.00 сәгатькә кадәр |
| 41 | Чирмешән | сишәмбе, җомга 8.00 сәгатьтән алып 12.00 сәгатькә кадәр |
| 42 | Чистай | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр; җомга 8.00 сәгатьтән алып 15.45 сәгатькә кадәр |
| 43 | Ютазы | сишәмбе 8.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр; җомга 8.00 сәгатьтән алып 15.45 сәгатькә кадәр |

Административ регламентка
7 нче кушымта

# Дәүләт вазыйфасын башкаруның блок-схемасы

